A. T.S.S.C. Qazan LENIN Isem. OLKO MASSA KITAPXANESE TOP KITAP SAQLAU BYLEGE
ОСНОВНОЕ КНИГОХРАНИЛИЩЕ ОБЛАСТНОЙ МАССОВОЙ им. ЛЕНИНА БИБЛИОТЕКИ АТССР г. Казань
Уг. К № 27

ПӘНҖЕШӘМБЕ
21 МАРТ
1940 ел
№ 66 (5866)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы бүлеге 4—58, партия бүлеге 18—22, совет төзелеше бүлеге 4—58, „Победа" колхозы ... бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

КОНФЕРЕНЦИЯ КАРАРЛАРЫН МАССАГА

Партиянең Татарстан оешмасының XXI нче өлкә конференциясе республикабыз тормышында гаять әһәмиятле булган карарлар кабул итте. Шушы елның 18 нче мартында игълан ителгән бу карарлар ВКП(б) ның Татарстандагы барлык оешмалары өчен, профсоюз, комсомол оешмалары һәм хуҗалык органнары өчен программ кулланма булып тора. Алар, партиябезнең тарихи XVIII нче съезды карарларын тулы һәм төгәл үтәүгә, республикабызның халык хуҗалыгын һәм культурасын тагын да кызуырак темплар белән үстерүгә юнәлдерелгәннәр.

ВКП(б) ның XXI нче өлкә конференциясе соңгы елларда республикабызның халык хуҗалыгы үсешендә алга таба гаять зур адым ясалганлыкны күрсәтеп үтте. Халык дошманнары тарафыннан эшләнгән корткычлык нәтиҗәләрен бетерү, Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгән яңа кадрларны тәрбияләү, үстерү һәм җитәкче эшләргә күтәрү буенча үткәрелгән эш нәтиҗәсендә, яңа уңышлар яулап алынды. Бу уңышлар конференция карарларында бик ачык күрсәтелделәр.

Шуның белән бергә, конференция республиканың партия, хуҗалык оешмалары алдына яңа, зур бурычлар куйды. Бик ачык ки, Татарстан промышленносте үзенең күләме һәм тоткан урны ягыннан өзлексез үсә баруына да карамастан, республиканың күп кенә предприятиеләре, тимер юл һәм су юлы транспорты, шулай ук төзү оешмалары һәм бигрәк тә төзү материаллары предприятиеләре 1939 нчы ел планын үтәмәделәр. Партиянең өлкә конференциясе аерым предприятиеләрнең бу җитешсезлекләрен „фабрикалар, заводлар һәм транспорт җитәкчеләренең, Татарстан республикасы наркоматлары җитәкчеләренең производство планнарын үтәү өчен көрәшне тиешенчә, большевикларча оештырмауларының, ә Татарстан АССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Өлкә Комитетының промышленность һәм транспорт эшенә кирәкле җитәкчелекне һәм контрольне тәэмин итмәүләренең нәтиҗәсе дип" санады. Шушылардан чыгып конференция партиянең барлык оешмалары алдына һәм хуҗалык органнары алдына конкрет бурычлар куйды. Конференция тарафыннан кабул ителгән карарда болай диелә:

— „Конференция партиянең республикадагы барлык оешмаларыннан һәм барлык хуҗалык оешмаларыннан промышленностьның, транспортның һәм промкооперациянең 1940 нчы елгы дәүләт планын үтәүне һәм шул ук вакытта промышленность продукциясенең 1939 нчы елгы планга караганда кимендә 14 процентка үсүен тәэмин итүне таләп итә". Сталинчыл өченче бишьеллык бурычларыннан чыгып билгеләнгән бу таләпне тулы һәм үз вакытында үтәү өчен көрәш—партия, профсоюз, комсомол оешмаларының һәм хуҗалык органнары җитәкчеләренең төп бурычлары булып тора. Моның өчен, барыннан да элек, стахановчылык хәрәкәтенә һәм күп станокчылар хәрәкәтенә җитәкчелекне көчәйтергә, предприятие администрациясенең эшенә партия оешмаларының контроль ясауларын большевикларча оештырырга, югары органнар тарафыннан чыгарылган карарларның үтәлешен системалы рәвештә тикшереп торырга кирәк.

ВКП(б) ның XXI нче өлкә конференциясе 1939 нчы елны республикабызда авыл хуҗалыгы эшләре планының үтәлеше һич тә канәгатьләнерлек булмавын, терлекчелек эше авыл хуҗалыгының аеруча артта калган тармагы булып калуда дәвам итүен күрсәтте. Республикабыздагы колхозларның һәм совхозларның техника белән нык коралланган булуларына, партия һәм хөкүмәт тарафыннан гаять зур игътибар бирелүгә дә карамастан, авыл хуҗалыгы эшләре планының бу рәвешле начар үтәлүе нәрсәдән килеп чыкты соң? Ул, барыннан да элек, җир органнарына һәм МТС ларга оператив җитәкчелек итмәүдән, артта калучы районнарга, МТС ларга һәм колхозларга вактында ярдәм күрсәтмәүдән һәм авыл хуҗалыгына җитәкчелек итү буенча партия райкомнарының эшен тиешенчә оештырмаудан килеп чыкты. Үткән елны авыл хуҗалыгы эшләре планының үтәлмәвен бары тик шуның белән генә аңлатырга мөмкин.

Партиянең өлкә конференциясе ВКП(б) Өлкә Комитетына, Совнаркомга һәм барлык партоешмаларга авыл хуҗалыгына җитәкчелек итүне яхшыртырга, колхозлар, совхозлар һәм МТС лар арасында социалистик ярышны киң җәелдерергә, авыл хуҗалыгы алдынгыларының тәҗрибәләрен барлык колхозчылар арасында популярлаштырырга тәкъдим итте. Партиянең авыл райкомнарының һәм колхозлардагы, совхозлардагы, МТС лардагы башлангыч партоешмаларның төп бурычлары—язгы чәчүгә үрнәк хәзерлекне тәэмин итүдән, 1940 нчы елны гектарыннан кимендә 13 центнер бөртекле культуралар уңышы алуга ирешү өчен көрәшүдән, терлекчелекне үстерү эшендә булган артталыкны бетерүдән гыйбарәт. Татарстан республикасы белән Чувашстан һәм Мордовия республикалары арасында төзелгән социалистик ярыш договоры, авыл хуҗалыгы өлкәсендә алдынгылык өчен көрәшнең төп этәргече булып хезмәт итәргә тиеш.

Конференция, халык мәгарифе органнары алдына, сәүдә оешмалары һәм суд-прокуратура органнары алдына да зур һәм җаваплы бурычлар куйды. ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын тулы тормышка ашыруны төп максат итеп куйган бу чаралар республикабызның һәрбер хезмәт иясенә җиткерелергә, барлык эшчеләр һәм колхозчылар массасы конференция карарларын үтәү көрәшенә тупланырга тиешләр. Партия, профсоюз, комсомол оешмалары республикабызның хезмәт ияләре арасында конференция карарларын киң популярлаштырырга, аны ныклап өйрәнүне оештырырга тиешләр. Бу эштә күп санлы агитаторлар кадрлары партия оешмаларына зур булышлык итә алалар һәм итәргә бурычлылар. Конференция карарларын массага, аны үтәү өчен көрәшкә! Партия оешмаларыннан хәзер әнә шул таләп ителә.

СОВЕТЛАР СОЮЗЫ БЕЛӘН ФИНЛЯНДИЯ АРАСЫНДАГЫ СОЛЫХ ДОГОВОРЫН СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫНЫҢ РАТИФИКАЦИЯЛӘВЕ ТУРЫНДА ТАСС БЕЛДЕРҮЕ

Шушы елның 19 нчы мартында СССР Верховный Советы Президиумы 1940 нчы елның 12 нче мартында Москвада Советлар Союзы белән Финляндия республикасы арасында төзелгән солых договорын ратификацияләде.

ФИНЛЯНДИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ СОВЕТ—ФИНЛЯНДИЯ СОЛЫХ ДОГОВОРЫН РАТИФИКАЦИЯЛӘДЕ

СТОКҺОЛЬМ, 17 март. (ТАСС). Кичә Финляндия республикасы президенты Каллио Советлар Союзы белән Финляндия арасында төзелгән солых договорын ратификацияләде. Президент договорның IX нчы статьясе нигезендә министр Паасикивины һәм сейм члены профессор Войонмааны Москвада ратификация актларын алмашырга вәкил итте.

Финляндия вәкилләренең—Паасикиви һәм Войонмаа әфәнделәрнең Москвага килүе

СССР белән Финляндия арасында төзелгән солых договорының ратификация актларын алмашу өчен Финляндия президенты тарафыннан вәкил ителгән Паасикиви һәм Войонмаа әфәнделәр 19 нчы мартта Москвага килделәр.

Аларны Үзәк аэропортта Наркоминделның Протоколлар Бүлеге мөдире иптәш В. Н. Барков, Балтыйк буе илләре Бүлеге мөдире иптәш А. К. Лысяк, Швеция миссиясенең хәрби атташесе Флодстрем әфәнде каршы алдылар.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

Актаныш районының „Кызыл Көч" колхозы хата - лабораториясендә. РӘСЕМДӘ (сулдан уңга): Звено башлыгы А. Ахметшин, бригадир С. Нургалеев һәм хата-лаборатория мөдире А. Ахметов иптәшләр занятиедә. А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ЧӘЧҮНЕ ТУЛЫ ХӘЗЕРЛЕК БЕЛӘН КАРШЫЛЫЙБЫЗ

Арча районы, „Кызыл тау" колхозы йөзпотчылар ярышына кушылып, быел югары иген уңышы алу буенча „Уңыш" һәм „Түбән Курса" колхозлары белән социалистик ярыш договоры төзегән иде. Колхозчылар договорны тулы үтәү өчен зур эш алып баралар. Колхозда 10 даими звено оештырылды. Шуларның икесе ефремовчы звенолар. Ярышып эшләүнең яхшы нәтиҗәләре күз алдында. Чәчү орлыклары җитәрлек хәзерләп, чистартылып куелды. Авыл хуҗалыгы машиналарына яхшы сыйфатлы ремонт ясалды һәм акт белән кабул ителде. Ат сбруйлары хәзер. Машиналарга ремонт ясауда тимерче Миңгали Нуриев, столяр Хәйреттин Шәмсеттинев һәм шорник Мөбарәк Сәйфеттинев иптәшләр аеруча яхшы эшләделәр.

Кышкы агрономия чаралары буенча да уңышлы бара. Басуга 750 йөк тирес чыгарылды, 250 гектарда кар тотылды һәм 40 центнер башка ашламалар хәзерләнде.

Колхозда стахановчылар мәктәбе эшли. Анда 5 занятие үткәрелде. Колхозда стахановчылар сафы көннән-көн үсә. Стахановчылар арасында Ахунҗан Тимербаев, Галимулла Хәбибуллин, Хәким Гатауллин, ат караучылардан Салах Мифтахов, Хуҗа Әхмәдуллин һәм Ситдиков иптәшләр яхшы үз күрсәткечләрен бирәләр.

Колхоздагы комсомол оешмасы хуҗалык эшләренә зур әһәмият бирә. Комсомол оешмасы үзенең җыелышларында колхоз тормышы мәсьәләләрен куя, аерым комсомолецларның информацияләрен тыңлый һәм колхоз правлениесенә эшлекле булышлык күрсәтә.

А. Маннапов.

Орлык белән колхозара ярдәмләшү

Чепья районында чәчүлек орлык белән колхозара ярдәмләшү киң күләмдә җәелдерелде. Шушы уңай белән колхозларда гомуми җыелышлар үткәрелә. Фрунзе исемендәге колхоз членнарының гомуми җыелышы колхозның үзеннән арткан 230 центнер чәчүлек орлыгын Сталин исемендәге колхозга бирергә карар чыгарды.

Районның „Трактор" колхозы „Кызыл Маяк" колхозына 75 центнер, „Алга" колхозы „Яңа Юл" колхозына 80 центнер орлык бирделәр.

Райондагы 28 колхоз үзләреннән арткан 1.900 центнер орлыкларын 21 колхозга бирәләр.

Х. Галләмов.

***

Дөбъяз районы, Яңа Авыл авылы, „Эшче" колхозы язгы чәчүгә яхшы хәзерләнә. Орлык туплау һәм тазарту тәгәлләнде. Колхоз үзеннән арткан орлыктан „Күмәк Көч" колхозына 50 центнер, „Туры юл" колхозына 35 центнер орлык бирде. Язгы чәчү өчен кирәкле машиналарга ремонт ясау да тәмам булды. Ремонтта эшләүче стахановчы иптәш З. Зарипов норманы һәр көн 150—200 процент үтәп барды. Ул хәзер урып-җыю машиналарын ремонтлау эшенә кереште һәм 3 лобогрейканы яхшы сыйфат белән ремонттан чыгарды инде.

Колхозда кырга 3.500 йөк тирес чыгарылды, 260 гектар җирдә кар тотылды, 65 центнер көл, 60 центнер кош тизәге һәм 60 центнер фекали җиналды.

З. Корбан.

ҮТКӘН ЕЛГЫ ЯЛГЫШЛАР КАБАТЛАНА

Норлат районында агротехника чараларын үткәрүгә җитәрлек әһәмият бирелми. Район җитәкчеләре бу эшне үз агымына куйлар. Басуга тирес чыгару планы 1937 нче елгы белән чагыштырганда 1938 нче елны 30 процентка, үткән елны 40 процентка кимеде. Былтыр тирес чыгару планы да бары 68 процентка үтәлде. Ленин исемендәге колхоз белән җир ашлаучы 50 процентка, „Победа" колхозы 60 процентка кимегән.

Агротехника чараларын үткәрүгә мондый ваемсыз карашны, билгеле, иген уңышына бик начар йогынты ясады. 1937 нче елда район буенча бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 15,48 центнер уңыш алынган булса, 1938 нче елда уңыш 8,72 центнерга, 1939 нчы елда 8,30 центнерга төште.

Район җитәкчеләре бу күңелсез халәттән нәтиҗә ясарга тиешләр иде. Ләкин алар барлык гаепне һава шартлары начар булуга гына кайтарып калдырдылар.

Районда язгы чәчүгә хәзерлек эше бик начар бара, агротехника чараларын үткәрүдә элеккеге ялгышлар кимчелекләр кабатлана. „Яналиф", „Кызыл Партизан" һәм Р. Люксембург исемендәге колхозлар басуга тирес чыгару, җирләре ашлау эшләренә әле башланганнары да юк. Максим Горький исемендәге колхозда чәчү орлыклары триерланмаган. „Победа" колхозына билгеләнгән минерал ашламалар Төрләмә станциясендә кар астында яталар. Районның күпчелек колхозларында агротехникага өйрәнү түгәрәкләре оештырылмаган.

Район җир бүлегендә (мөдире иптәш Гыймранов) колхозларда агротехника чараларын үткәрү буенча үчет бик начар куелган. Җирле ашламалар хәзерләү планы кайбер колхозларда бер дә үтәлмәгән. Мәсәлән, Ленин исемендәге колхоз үткән ел басуга 18 мең йөк тирес чыгарган, ә аңар быел район җир бүлеге бары 4.500 йөк план биргән. Кайбер колхозларга план бирелмәгән дә билгеле түгел. Җир бүлеге агрономнары колхозларда бик сирәк булалар.

Иәзлектәчләр хәрәкәтенә кушылганнан соң районда 17 колхозда стахановчылар мәктәпләре оештырылган иде. Ләкин бу мәктәпләрнең күбесендә занятиеләр системалы рәвештә барылмый. „Татарстан" һәм „Совет" колхозларында даими занятиеләр оештырылмаган. Кайбер колхозларда даими звенолар оештырылмаган, звеноларга җир беркетелмәгән.

Хәбиб Хәлилев.

МТС ларда тракторларга ремонт ясауның барышы турында Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты сводкасы

1940 нчы елның 15 нче мартына

(Көзге-кышкы ремонт планына карата процентларда)

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
Нөркәй	100	Чишмә	83,3	Ютазы	68,5
Тымытык	100	Аксубай	83,3	Питрәч	66,1
Теләче	100	Мәлки	83,3	Биләр	66,0
Кама Тамагы	100	Норлат	82,6	Юдино	66,0
Маткавыш	100	Әлки	82,0	Иске Тимошкино	65,9
Актаныш	100	Исәнбай	81,6	Кузнечиха	64,8
Мөслим	100	Тәкәнеш	81,0	Соколка	64,4
Янил	100	Зур Поляна	81,0	Мортовский	63,8
Чалпы	100	Тәтеш	80,8	Кызыл Йолдыз	63,6
Алга	100	Калинин	79,6	Кузайкино	63,5
Кадрәк	100	Саба	79,5	Тат. Ялтан	63,0
Тирсә	100	Мамадыш	77,8	Рождественский	62,3
Т. Тамак	100	Шөгер	76,5	Татходяш	61,7
Минзәлә	100	Әтнә	76,0	Үзәк	61,5
Иске Чишмә	100	Биектау	75,5	Мәйдан	61,3
Юртыш	100	Мөслим (Чистай)	75,0	Иске Писмән	61,1
Азин	100	Кызыл Юл	74,6	Дөбъяз	61,0
Әлмәт	100	Алабуга	74,5	Яңа Чишмә	60,0
Балтач	100	Макыл	74,5	Димитровский	60,0
Беренче Май	100	Буа	74,4	Чокалы	58,2
Черемуховский	97,6	Әлши	73,8	Карамалы	57,1
Кызыл Чапчак	96,0	Олы Карилле	72,9	Константиновский	56,2
Ишеево	94,1	Кәкре Елга	72,7	Поповский	55,1
Чаллы	93,7	Кошкинский	72,5	Мөрәле	55,1
Кукмара	93,6	Акташ	72,2	Алексеевский	54,5
Чистай	93,3	Зирекле	70,7	Ромадановский	54,5
Тархан	93,0	Арча	70,6	Тельман	48,0
Чүпрәле	92,7	Салман	70,6	Заинский	45,1
Буденный	89,1	Чиябаш	70,6	Зөя	41,1
Куйбышев	88,0	Әхмәмәт	70,5		
Сарман	87,9	Базарлы Матак	70,4		
Октябрь	87,5	Балык Бистәсе	70,2	Барлыгы	77,1
Дәүләки	87,5	Трехозерский	70,0		
Столбище	87,3	Чүрибураш	69,8	1940 нчы елның	
Чыбыклы	86,5	Каргалы	69,6		
Бондюг	86,0	Бөгелмә	69,0	10 нчы мартына	74,0
Кичү	85,2	Баулы	68,7		

ТАССНЫҢ ЮККА ЧЫГАРУЫ

Чит ил матбугатында гуяки Финляндия белән Швеция һәм Норвегия арасында „оборона союзы" дип аталган нәрсә төзү турында сөйләшүләр алып бару һәм бу союзның бурычы Финляндиянең чикләрен хәрби яктан саклаудан гыйбарәт икәнлеге хәбәр ителә. Шул ук вакытта гуяки Советлар Союзының Финляндия белән Швеция һәм Норвегия арасында мондый „оборона союзы" төзүгә каршы килмәгәнлеге хәбәр ителә.

Советлар Союзының позициясе турында бу хәбәрләрнең дөрес түгеллеген белдерергә ТАСС ның вәкаләте бар, чөнки Норвегиянең стортинг председателе Хамбро әфәнденең 14 нче мартта Советка каршы сөйләгән маглүм речендән күренгәнчә, мондый союз СССР га каршы юнәлдерелгән булыр иде һәм СССР белән Финляндия арасында шушы елның 12 нче мартында төзелгән солых договорына турыдан-туры капма-каршы килер иде.

Һиндстандагы хәл

ЛОНДОН, 18 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Һиндстан милли конгрессының сессиясе бара торган урыннан—Рамгардан (Һиндстанның үзәк провинцияләре) берничә километр ераклыкта Англия белән килешүгә каршы кешеләрнең „компромисска каршы" конференциясе җыелган. Конференциягә Бос һәм Һиндстан конгрессының сул канатының башка эшлеклеләре җитәкчелек итәләр. Конференциядә Һинд халкының бәйсезлеккә аерылгысыз хокукын тагын бер кат күрсәтеп резолюция кабул ителгән. Резолюциядә халыклар массасыннан яшерен рәвештә Англия белән килешергә һәр төрле маташу Һиндстанның бәйсезлек урнына „коллыкның башка формасын" гына алуына китерәчәк дип күрсәтелә.

НЬЮ-ЙОРК, 19 март. (ТАСС). Юнайтед пресснең Рамгардан (Һиндстан) хәбәр итүенә карагандa, „компромисска каршы" блокның (Англия белән килешүгә каршылар) вәкиле блокның килешүләр белән хисаплашмыйча көрәш программасын тормышка ашыруны дәвам иттерүне үзенең бурычы дип санаганлыгын белдергән.

ЛОНДОН, 19 март. (ТАСС). Рейтерның Рамгардан хәбәр итүенә караганда, „компромисска каршы" бөтен Һиндстан конференциясенең председателе Бос Гандины һәм конгрессның уң канатының хәзерге җитәкчелеген гаепләп хат белән мөрәҗәгать иткән. Бос җитәкчелекне „ялган учредительный собрание" чакыруны таләп итеп җитәкчелекнең дөрес юлдан тайпылуын гаепли.

Бос, империализм белән килешү политикасы тормышка аша калса Һиндстандагы сул даирәләрнең империализмга каршы гына түгел, бәлки аның һиндле союзникларына каршы да көрәшәчәкләрен белдергән.

Гитлерның Муссолини белән очрашуы

БЕРЛИН, 18 март. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, бүген иртә белән Бреннерда (Германия—Италия чигендә) Гитлерның һәм Риббентропның Муссолини һәм Чиано белән очрашуы булган.

Муссолининың салон—вагонында 2 сәгать ярым буена дусларча беседа булган.

ЛОНДОН, 18 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгы бүген 13 сәгаттә Гитлерның Бреннердан Берлингә китүе турында үзенең Римдагы хәбәрчесенең белдерүен тапшыра. 15 минут үткәч Муссолини дә Римга киткән.

Гитлерның Муссолини белән очрашуы турында Германия матбугаты

БЕРЛИН, 19 март. (ТАСС). Берлин матбугаты Гитлерның Муссолини белән очрашуы турында күп яза. Очрашуга барлык газеталар зур мәкаләләр багышлыйлар. „Фелькишер беобахтер" „Бреннердагы беседа вактында гадәттән тыш әһәмиятле карарлар кабул ителде" дип яза. Газетаның язуына караганда, Гитлерның Муссолини белән очрашуы Германия белән Италия арасындагы элемтәне һәм дуслык мөнәсәбәтләрен тагын бер кат күрсәткән.

„Берлинер берзенцейтунг" газетасы Италия—Германия дуслыгының ныгуы Гитлерның Муссолини белән очрашуының нәтиҗәсе булыр дип яза. „Ике илнең дуслыгы торган саен көчлерәк һәм тыгызрак була бара. Көнбатыш Европа дәүләтләрендә әле һаман да интригалар юлы белән Германиянең Италия белән союзын өзәргә мөмкин дип уйлыйлар. Алар Германия—Италия дуслыгын бер кайчан да җимерә алмаслар.

Европаның төньягында җинаятьле планнары уңышсыз чыкканнан соң, көнбатыш державалар үзләренең карашларын көньякка, Италиягә юнәлтергә маташалар. Күмер турында Германия—Италия килешүе бу маташуларга беренче җавап иде, ә Бреннерда күрешү—икенче җавап булды".

Эссенда чыга торган „Националь цейтунг" газетасы болай дип яза: „Германия—Италия мөнәсәбәтләре договор нигезендәге йөкләмәләргә нигезләнәләр. Аларны Көнбатыш Европа матбугатының бернинди ялган кампаниясе дә өзә алмас. Гитлер белән Муссолини арасындагы беседа вактында нәрсә турында гына сөйләнмәсен, бу очрашу Германия белән Италиянең дуслыгын тагын да ныгытуга китерәчәк".

„Дейче альгемейне цейтунг" газетасы „Союз турындагы договор белән бәйле булган бөек державалар үзләренә кагылышлы әһәмиятле мәсьәләләрне тикшерделәр" дип яза.

Партия тормышы

АВЫЛ ИНТЕЛЛИГЕНЦИЯСЕ

ВКП(б) нын Норлат район оешмасы партиябезнең XVIII нче съездыннан соң интеллигенция арасында политик-масса эшен шактый яхшыртты. Шунын нәтиҗәсе буларак, интеллигенция арасында партиягә керү омтылышы көчәйде. Партиябезнең XVIII нче съездыннан соң алдынгы интеллигентлардан 110 кеше ВКП(б) сафларына кабул ителде. Партиягә яна алынган иптәшләр арасында Норлат урта мәктәбе директоры Хәсәнев, судья Әминев, агроном Мостафин, Карашәм авыл советы председателе Гыйниятуллин иптәшләр бар.

Район интеллигенциясеннән 183 кеше „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н үзлекләреннән өйрәнә. Молвино авылы тулы булмаган урта мәктәп директоры Сафин, Тат. Танай авылы тулы булмаган урта мәктәп директоры Сагдиев иптәшләр „Кыскача курс" нын XII бүлеген дә өйрәнү эшен тәмамладылар. Хәзер бу иптәшләр партиябезнең героик тарихын төп чыганаклардан өйрәнәләр.

Авыл интеллигенциясенә үзләренең политик-теоретик белемнәрен күтәрүдә башлангыч партоешмалар зур булышлык күрсәтәләр. Мәсәлән, „Активист" һәм Ленин исемендәге колхозларда ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләр өчен лекцияләр үткәрелә һәм консультацияләр оештырыла.

М. Гыйсмәтуллин.

Кандидатлар арасында эшләү җитәрлек түгел

ВКП(б) нын Алабуга район оешмасында кандидатлык стажлары күптәннән чыккан 35 кеше исәпләнә. Алар арасында 6—9 еллар буена ВКП(б) членлыгына кандидат булып торучы иптәшләр бар. Мәсәлән, крахмал заводында эшләүче Мөхәммәттинова һәм механика заводында эшләүче Семин иптәшләр 1932 нче елдан бирле кандидат булып торалар. Кандидатлар арасында производство алдынгылары аз түгел. Мәсәлән, механика заводында эшләүче шул ук Семин һәм Сухов иптәшләр көнлек эш нормаларын системалы рәвештә арттырып үтиләр. Ләкин, аларның политик яктан үсүләре турында завод партоешмасы тарафыннан кайгыртучанлык юк. Гассар исемендәге һәм Юраш авылы Сталин исемендәге колхозлар янындагы партоешмаларда, крахмал заводы янындагы кандидатлар группасында кандидатлар арасында бер төрле дә политик-тәрбия эшләре алып барылмый.

С. Сафиуллин.

Язгы чәчү алдыннан. РӘСЕМДӘ: Актаныш районының „Кызыл Көч" колхозы янындагы башлангыч партоешма ефремовчы звеноларның чәчү нормасын тикшерә. А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Рекомендация бирүгә җиңел караш

Партия сафларына керергә теләүче кешеләргә рекомендацияләр бирү мәсьәләсе бик җаваплы эш. Ләкин моны кайбер коммунистлар тиешенчә аңлап җиткермәгәннәр әле. Кукмара районында аерым коммунистлар бу мәсьәләдә аеруча җавапсызлык күрсәтәләр. Мәсәлән, район Советы башкарма комитеты председателе иптәш Нигматуллин партиягә керү өчен Х. дигән кешегә рекомендация биргән, ә аның социаль чыгышы белән кызыксынмаган. Тикшерү нәтиҗәсендә аның социаль чыгышы чит булуы беленде. Никитин һәм Германов иптәшләр С. дигән кешенең үткәннәрен, хәзерге хәлен һәм аның үзен ничек тотуын яхшылап тикшермичә аңар рекомендация биргәннәр. Ныклап тикшерү нәтиҗәсендә, С. нын партиябез өчен лаеклы булмаганлыгы беленде. Мәсәлән, С. эчүчелек белән шөгылләнә. Җинаят эшләве өчен суд җаваплылыгына тарттырылган булган. Аның якыннары сектантлар группасына җитәкчелек иткәннәр. Гумеров һәм Закирова иптәшләр тарафыннан А. га рекомендация бирелгән. Ә, тикшерү нәтиҗәсендә А. нын эре сәүдәгәр кызы булуы беленгән.

Билгеле, бу кешеләрнең үзләрен партиягә кабул ителүләрен сорап биргән гаризаларын ВКП(б) райкомы кире какты.

Тагын шуны әйтергә кирәк, ВКП (б) членнарыннан Медведев („Ил" артеленең председателе), Хәбибуллин (раймаг директоры) иптәшләр бергә эшләү буенча бөтенләй таныш булмаган кешеләргә рекомендация бирү белән шөгылләнгәннәр. Бу фактлар райондагы аерым коммунистларның ВКП(б) уставын яхшы белмәүләрен күрсәтә. Рекомендация бирү эшенә җавапсыз караш бетерелергә һәм бу турыда ВКП(б) уставы таләпләре тулысынча үтәлергә тиеш.

Ә. Солтанов.

Авыл коммунистлары актив эш алып баралар

Кукмара районы, Мәчкәрә авылында ВКП(б) нын XVIII нче съездыннан соң башлангыч партоешма оештырылган иде. Партоешма, шушы кыска гына вакыт эчендә ВКП(б) членлыгына кандидат итеп 6 кеше, ВКП(б) га член итеп 4 кеше кабул итте. Башлангыч оешма партия сафларын авылның алдынгы кешеләре хисабына үстерү белән бергә рәттән, яш коммунистларны большевизм рухында тәрбияләүгә җидди игтибар бирә. Коммунистларның барысы да „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н үзлекләреннән өйрәнәләр. Партия тарихын өйрәнүчеләр өчен индивидуаль һәм групповой консультацияләр оештырыла.

Коммунистларның политик белем дәрәҗәләре үсү белән бергә, производствода авангардлык рольләре дә күтәрелә бара. Алар колхозда йөзпотчылар хәрәкәтен җәелдерүдә зур инициатива күрсәтәләр. Шуның белән бергә, җәмагат эшләренә актив катнашалар. Коммунистлардан 4 кеше колхозда агитатор булып эшли.

Яш коммунистлардан җитәкче кадрлар үсеп чыктылар. Җирле Советларга сайлаулар вактында коммунистлардан Сираҗиев, Фәйзерахманов, Шакирҗанов иптәшләр авыл Советына депутат итеп, Сәдыйков һәм Нурмөхәммәтов иптәшләр район Советына депутатлар итеп сайландылар. Шуның белән бергә, иптәш Шакирҗанов авыл советы председателе итеп, иптәш Шакиров колхоз председателе итеп сайландылар.

Г. Сибгатуллин.

ВКП(б) ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮЧЕЛӘРГӘ ЯРДӘМГӘ

КРЕСТЬЯН МӘСЬӘЛӘСЕ ТУРЫНДА ЛЕНИННЕҢ ӨЧ ЛОЗУНГЫСЫ

(ВКП(б) Өлкә Комитеты лекторы иптәш Һазиров лекциясеннән кыскартып алынды)

Революцион көрәштә эшчеләр сыйныфының төп максаты булып коммунизм җәмгыятен төзү тора. Моның өчен эшчеләр сыйныфы властьны үз кулына яулап алып, пролетариат диктатурасын төзергә тиеш.

Маркс һәм Энгельс пролетариатның союзниклары мәсьәләсе белән бик нык кызыксындылар. Аларның фикере буенча хезмәт иясе крестьяннарның күпчелеге пролетариатның союзнигы була ала. 1856 нчы елны Энгельска язган хатында Карл Маркс болай ди: „Германиядә бөтен эш пролетар революциясе крестьяннар сугышының нинди дә булса икенче тапкыр кабатлануы белән яклау мөмкинлегенә бәйләнгән булачак" (Карл Маркс, сайланма әсәрләр, том II, бит 314, 1937 нче ел басма).

1894 нче елда үзенең „Франциядә һәм Германиядә крестьяннар мәсьәләсе" дигән мәкаләсендә Энгельс болай дип язды:

„Социалистик партиянең политик власть яулап алуы инде шактый якынайды. Ләкин политик властьны яулап алу өчен бу партия иң элек шәһәрдән авылга барырга тиеш, анда көчле булып әверелергә тиеш" (Энгельс, „Франциядә һәм Германиядә крестьяннар мәсьәләсе", бит 9, 1937 нче елгы басма).

Вак хосуси милеккә нык бәйле крестьяннар социализмга каршы булачаклар, дип аларны социалистик эре җәмагат хуҗалыгы юлына кертү мөмкин булмаган эш дип караучы скептикларга каршы Энгельс болай ди:

„Без кискен көрәштә вак крестьян ягында торабыз; без аның язмышын җиңелрәк итү өчен, әгәр дә ул үзе карар бирсә, аның товариществога күчүен җиңеләйтү өчен бөтен мөмкин булган нәрсәләрне эшләячәкбез; һәм хәтта, әгәр дә ул әле бу карарга килерлек хәлдә булмаса, аңа үзенең бер кисәк җире өстендә бу турыда уйланырга да вакыт бирәчәкбез" (шунда ук, бит 29).

Димәк, Маркс һәм Энгельс эшчеләр сыйныфы белән хезмәт иясе крестьяннәр союзы ягында торалар һәм бу союзның булуына бик нык ышаналар.

Ләкин II нче Интернационал партияләре марксизмның бу положениесен бозарга тырыштылар. Алар социалистик революциягә һәм пролетариат диктатурасына каршы чыктылар. Шуңа күрә дә алар эшчеләр сыйныфының союзниклары мәсьәләсе белән кызыксынмадылар. Эшчеләр сыйныфын либерал буржуа иярченә әверелдерергә тырыштылар. Алар крестьяннарны реакцион көч дип санадылар. Мәсәлән, меньшевик Плеханов: „буржуазиядән һәм пролетариаттан башка бездә оппозицион яки революцион комбинацияләр таяна ала торган башка иҗтимагый көчләрне күрмибез" (ВКП(б) тарихы, бит 85) дип язды.

***

Большевиклар партиясе, Ленин һәм Сталин революцион эшләренең беренче көннәреннән үк крестьян мәсьәләсе белән җидди рәвештә кызыксындылар. В. И. Ленин үзенең беренче хезмәтләрендә үк бу мәсьәләгә тирән анализ ясады.

Крестьян мәсьәләсе бигрәк тә 1905 нче елгы революция алдыннан зур урын алды. Бу вакытта безнең ил буржуаз демократик революция алдында тора иде. Буржуаз демократик революциядә пролетариат гегемониясе өчен һәм буржуаз-демократик революциянең социалистик революциягә әверелеп үсүе өчен көрәшүче большевиклар партиясенең крестьян мәсьәләсе белән җидди рәвештә шөгылләнүе табигый нәрсә иде.

1905 нче елның апрелендә партиянең III нче съезды чакырылды. Революция тарафыннан куелган мәсьәләләргә карата съезд партиянең тактик линиясен билгеләде. Шул ук елның июлендә В. И. Ленин үзенең „Демократик революциядә социал-демократиянең ике тактикасы" дигән китабын язды. Ленин үзенең бу китабында меньшевикларның оппортунистик линияләрен фаш итте, большевистик линияне даһиларча нигезләде.

В. И. Ленин 1905 нче елгы революцияне буржуаз-демократик революция, бу бөтен эшчеләр сыйныфын һәм крестьяннарне хәрәкәткә китерә торган революция, дип карады. Царизмны бәреп төшерү, пролетариатның һәм крестьяннарның революцион диктатурасын төзү, эшчеләргә 8 сәгатьлек эш көнен яулап алу, алпавытларның җирләренә конфескация ясау революция алдында торган якын киләчәкнең төп бурычлары икәнен күрсәтте. Буржуаз-демократик революциядә эшчеләр сыйныфы гегемониясен нигезләде. Эшчеләр сыйныфы гегемониясен тормышка үткәрү өчен, беренчедән, аның союзнигы булырга тиеш иде. Мондый союзник булып крестьяннәр тора иде. Икенчедән, революциядә җитәкчелек ролен үзенә алу өчен көрәшүче либерал буржуазияне изоляцияләргә кирәк иде. Шушы бурычлардан чыгып, буржуаз-демократик революциянең бу этапы өчен В. И. Ленин түбәндәге тарихи лозунгны бирде:

„Самодержавиянең каршылык күрсәтүен көч белән изеп ташлау һәм буржуазиянең тотрыксызлыгын параличлау өчен, пролетариат, үзенә крестьяннәр массасын кушып, демократик переворотны ахырына кадәр үткәрергә тиеш".

(Ленин. Сайланма әсәрләр, том I, бит 431, Татгосиздат, 1939 ел).

Димәк, революциянең беренче этапына карата булган лозунг шуннан гыйбарәт: „буржуазияне битараф иткән хәлдә, барлык крестьяннәр белән бергәләшеп, патшага һәм алпавытларга каршы буржуаз - демократик революциянең җиңүе өчен" (Сталин, „Ленинизм мәсьәләләре" бит 174). В.И. Ленинның бу лозунгысы крестьяннәргә карата булган төп лозунгларның беренчесе. Бу лозунг нигезендә безнең партиябез буржуаз-демократик революциядә эшчеләр сыйныфы белән крестьяннәрнең ныклы союзын һәм бу союзда эшчеләр сыйныфының җитәкчелеген тәэмин итә алды.

Буржуаз-демократик революция чоры 1905 нче елгы революция белән 1917 нче елгы февраль революциясе арасындагы вакытны үз эченә ала. Бу чорда пролетариат белән либерал буржуазия арасында крестьяннәрне үз якларына карату өчен кискен көрәш барды. Дүрт дума чоры, 1914 нче елда башланган империалистик сугыш либерал буржуазиянең патша һәм алпавытлар яклы икәнен, аның крестьяннәргә җир дә, солых та бирә алмавын ачык күрсәтте. Кабаладан, империалистик сугыштан коткаруга ярдәм итә ала торган бердән-бер көч эшчеләр сыйныфы гына икәнен крестьяннәр үз тәҗрибәләрендә күрделәр. Пролетариат җитәкчелегенә буйсындылар, либерал буржуазия изоляцияләнде.

„Әнә шуңа күрә крестьяннәр кадетлардан китеп, эсерларга тукталып, шуның белән бергә, рус пролетариаты шикелле, революциянең шундый батыр юлбашчысының җитәкчелегенә буйсыну зарурлыгына килделәр" (Сталин, "Ленинизм мәсьәләләре", бит 43).

Нәтиҗәдә, большевиклар партиясе җитәкчелегендәге эшчеләр сыйныфы, крестьяннәр белән союзда булып, 1917 нче елгы февраль революциясендә патша самодержавиясен власть башыннан бәреп төшерде.

***

Социалистик революциядә эшчеләр сыйныфы шәһәр һәм авыл буржуазиясенә каршы көрәш алып бара. Бу көрәштә ул крестьяннәрнең барлык катлауларына да таяна алмый. Авылның ярым пролетарийлары аның ныклы союзнигы. Урта хәлле крестьян бер яктан хосуси милек иясе, икенче яктан ул үз хезмәте белән көн күрә. Ул еллар буенча җыеп килгән аз-маз милкен югалтудан курка. Шуңа күрә дә ул революция белән контрреволюция арасында аумакайлана. Кем кемне җиңүен көтә, „көтеп тору" позициясендә була.

Буржуаз-демократик революциядән соң сыйнфый көчләрнең янадан төркемләшүеннән чыгып, социалистик революция этапы өчен Ленин икенче төп лозунгы бирде:

„Буржуазиянең каршылык күрсәтүен көч белән вату, крестьяннәрнең һәм вак буржуазиянең тотрыксызлыгын параличлау өчен, пролетариат, үзенә халыкның ярым пролетар элементлары массасын кушып, социалистик переворот ясарга тиеш"

(Ленин. Сайланма әсәрләр. том I, бит 431).

Димәк, Ленинның революциянең икенче этапы өчен биргән төп лозунгысы шуннан гыйбарәт: „урта хәлле крестьяннәрне битараф иткән хәлдә, ярлы крестьяннәр белән бергәләшеп, шәһәрдә һәм авылда капитализмга каршы, пролетариат власте өчен" (Сталин. „Ленинизм мәсьәләләре", бит 174). Бу крестьяннәргә карата булган икенче төп лозунг иде.

Социалистик революцияне хәзерләү һәм аны үткәрү чоры 1917 нче елгы февраль революциясеннән алып, 1917 нче елгы Октябрь революциясе арасындагы вакытны үз эченә ала. Бу чорда эсерлар крестьяннәрнең күпчелеген үз ягына яулап алу өчен көрәштеләр. Ләкин большевиклар җиңде: крестьяннәрнең күпчелеге большевиклар ягында булды. Кабаладан котылу, җир һәм солых алу өчен бердән-бер юл буржуазия, эсерлар, меньшевиклар властен бәреп төшерүгә бәйләнгән икәнлекне крестьяннәрнең күпчелеге күрде һәм эсерларны ташлап пролетариат тирәсенә тупланды.

„Бу чорның характерлы сыйфаты: крестьяннәрнең тагын да революционлашуыннан, аларның эсерлардан өмет өзүеннән, крестьяннәрнең эсерлардан китүеннән, крестьяннәрнең илне солыхка китерергә сәләтле, бердән-бер ахыргача революцион көч булган пролетариат тирәсенә **турыдан-туры туплану** ягына яңа **борылышыннан** гыйбарәт" (Сталин, „Ленинизм мәсьәләләре", бит 44).

Нәтиҗәдә, Бөек Октябрь Социалистик революциясе җиңде.

***

1917 нче елгы Бөек Октябрь Социалистик революциясе капиталистларны, алпавытларны власть башыннан алып ташлады. Алпавытларның, монастырьларның, дәүләт феодалларының җирләрен крестьяннәргә бирде. Ләкин бу әле беренче генә адым иде. Хәзер социалистик революциянең иң төп һәм иң кыен мәсьәләсен— вак таркау крестьян хуҗалыгын социалистик җәмагат хуҗалыгы юлына күчерү мәсьәләсен хәл итү кирәк иде. Социалистик хуҗалыкны төзү эшчеләр сыйныфының урта хәлле крестьян белән ныклы союзыннан башка мөмкин түгел иде. Октябрь революциясеннән соң авыл урта хәллегә әверелде. Сугышка кадәр крестьяннәр арасында ярлылар 65 процент, урта хәлләләр 20 процент чамасы булса, Октябрь революциясеннән соң урта хәлләләр 60 процентка җитте. Урта хәлле авылның төп фигурасына әйләнде. Советлар власте ныгыгач, урта хәлле үзе дә Советларга таба җидди рәвештә борылыш ясады.

1918 нче елның ноябрендә Ленин крестьяннәр мәсьәләсе буенча өченче лозунгны бирде:

„Кулакка каршы көрәштән бер генә минутка да баш тартмыйча һәм бары тик ярлыларга гына нык таянып—урта хәлле крестьяннәр белән килешү ясауга ирешә белергә" (Ленин, т. XXIII, бит 294) диде.

Урта хәлленең артталыкларына каршы көрәшүне ышандыру юлы белән алып барырга кирәклекне, авылда социалистик чараларны үткәргәндә ирексезләүләргә юл куймаска тиешлекне VIII нче съезд кисәтеп үтте. Шул ук вакытта бу мәсьәләдә пролетариатның җитәкчелеге тәэмин ителергә тиешлек турында әйтелде.

Кызып барган гражданнар сугышы социалистик төзелешкә тоткарлык ясады. Хәрби коммунизм политикасы үткәрелде. Бу вакытта эшче-крестьян элемтәсенең нигезендә хәрби-политик союз ятты.

Гражданнар сугышы беткәннән соң илебез яңа экономик политикага күчте. Бу вакытта илебезнең экономикасында төрле-төрле иҗтимагый - экономик укладларның элементлары яши иде. Шулар эчендә күпчелек урынны вак товар производствосы хуҗалыклары тәшкил итә иде.

Шушы яңа экономик политика шартларында крестьяннәрне социалистик эре хуҗалык юлына тарту формаларын табарга кирәк иде. Бу нәрсә Ленинның кооперативлаштыру планында ачык күрсәтелде.

Иптәш Сталин кооперативлаштыру планын тагын да үстерде һәм баетты.

Партиянең XV нче съезды авыл хуҗалыгын коллективлаштыру съезды булды. Бу съезд авыл хуҗалыгын коллективлаштыру турында ачык директивалар бирде.

Иптәш Сталин җитәкчелегендә партия елдан-ел эшче сыйныфы белән урта хәлләләрнең союзын ныгыта барды. Социалистик хуҗалык юлына керү өчен крестьяннәр сафларында бөек борылыш хәзерләде. 1929 нчы ел бөек борылыш елы булды. Урта хәлле крестьяннәр колхозларга күпләп керә башладылар. Кулаклар сыйныф булу ягыннан бетерелделәр. Элек авылда Совет властеның чын таянычы ярлылар булса, тоташ коллективлашудан соң „колхоз крестьяннәре Совет властеның чын һәм ныклы таянычы" булып әверелделәр.

***

Крестьяннәр мәсьәләсе буенча В. И. Ленинның бу төп өч лозунгысын тормышка үткәрү тыныч кына, үзлегеннән агылыш юлы белән бармады. Бу лозунгларны бозарга теләүчеләргә каршы революциянең барлык этапларында да кискен көрәш алып барылды.

В. И. Ленинның бу лозунглары нигезендә, хезмәт ияләре бөтен эксплоататор сыйныфларны җиңде. Илебездә социалистик җәмгыят төзелде.

КИТАП ӨСТЕНДӘ ҮЗЛЕГЕҢНӘН ЭШЛӘҮНЕҢ КАЙБЕР ТӘҖРИБӘЛӘРЕ

Марксизм-ленинизм нигезләрен үзлегеңнән өйрәнүдә китап өстендә эшләүнең методик алымнары мәсьәләсе гаять зур әһәмиятле урын тота. Хәзер бездә бик күп иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н үзлекләреннән өйрәнәләр һәм аларның саны көннән-көн арта бара. Бу эшкә яңа керешүчеләр өчен китап өстендә үзлегеңнән эшләү методлары буенча тәҗрибә уртаклашуның әһәмияте аеруча зур. Шунлыктан, мин „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н урта буын буенча өйрәнгәндә китап өстендә ничек эшләвем һәм ничек конспект төзүем турында үземнең кайбер тәҗрибәләрем белән уртаклашырга уйлыйм.

„ВКП(б) тарихының кыскача курсы" басылып чыгу белән үк, аны үзлегемнән укырга керештем. Үзлегеңнән укыганда китапны аңлап уку һәм аңлаганны конспектлаштыру өчен бу мөһим эшнең методик алымнарын белү кирәклеген мин ачык аңладым. Бу эштә миңа „Пропагандист" һәм „В помощ Марксистско—Ленинскому образованию" журналларында басылган материаллар зур ярдәм иттеләр.

„Кыскача курс"ны өйрәнгәндә, беренче чиратта, шул китап күләмендә бирелгән мәсьәләләрне яхшылап аңлауны төп бурыч итеп куйдым. Шуның өчен укыган өлешне тәмам аңлауга нык игтибар бирдем. Укып аңлаганны язып бару, конспектлауда күп кенә методлар кулланырга туры килде. Укыганда „Кыскача курс" нын аерым бүлеген бер бөтен итеп алам һәм андагы бүлекчәләрдә куелган мәсьәләләрне карап чыгам. Болай эшләү бүлектә нинди төп мәсьәләләр турында язылганлыгын һәм ул бүлекнең кайсы чорны эченә алуын башлангыч рәвештә булса да күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Шуннан соң инде аерым бүлекчәләр буенча укуны дәвам иттерәм. Укыганда үзем аңларга тиешле төп сораулар итеп, бүлекчә башында бирелгән төп мәсьәләләрне хәтердә тотам һәм шул мәсьәләләрнең беренчесенә карата кайсы урынга кадәр, икенчесенә карата кайсы урынга кадәр язылуга нык игтибар итәм. Шул ук вакытта бу урыннарны тиз табу өчен китапның читенә аерым билгеләр куеп барам. Бу билгеләр конспект язганда эшне шактый җиңеләйтә.

Мәсәлән, „Кыскача курс"ның VII нче бүлегенең беренче бүлекчәсендә:

„Февраль революциясеннән соң илдәге обстановка. Партиянең подпольедән чыгуы һәм ачык политик эшкә күчүе. Ленинның Петроградка кайтуы. Ленинның апрель тезислары. Партиянең социалистик революциягә күчү установкасы" дигән төп мәсьәләләр алына. Бу мәсьәләләргә китапта 7 бит урын бирелгән. Шундый бүлекчәләрне укыганда куелган төп мәсьәләләргә кай урында һәм нинди җавап бирелүен билгеләп бару белән бергә, шул мәсьәләләргә карата китерелгән дәлилләрнең һәм кыскача нәтиҗәләрнең дә кай урында булуына игтибар итәм һәм аерым билгеләр куеп барам. Мин һәр мәсьәләгә карата аерым билгеләр алдым. Бирелгән сорауга җавап булып килгән төп фикер язылган урынның астына (юл арасына) бер сызык сызам. Шул фикерне раслау өчен китерелгән дәлилләрне үземнең конспектымда алырга уйласам, шул турыга китапның читенә буйга бер сызыкча куям. Кыскача нәтиҗә бирелгән урында читкә ике сызык сызам. Шулар өстенә минем тагын ике билгем бар. Укыганда үзем аңламаган терминнар булса, аларны аерым дәфтәргә язып барам. Бу инде көтепханәдә сүзлек белән эш иткәндә минем эшне җиңеләйтә. Аннан соң аерым урыннарны тирәнрәк итеп аңлау өчен өстәмә материал укырга, яки консультация алырга кирәк дип санасам, кайсы урында һәм нинди мәсьәләнең аңлашылмавын аерым билге астына алам. Бу хәл миңа нинди өстәмә материаллар укырга һәм нинди темаларда консультация алырга кирәклекне ачык күрсәтеп тора.

Беренче кат укыганда үзем билгеләп киткән урыннарны тагын бер кат укып чыкканнан соң һәм аңлашылмаган мәсьәләләрне хәл иткәннән соң гына конспект төзү эшенә керешәм. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н үзлегемнән өйрәнүне шушы метод белән алып бару миңа укыганнарны яхшылап аңларга, төзелгән конспектның системалы һәм аңлаешлы булуына зур ярдәм итте. Мондый метод белән өйрәнгәндә конспект язу эшенә дә бик аз вакыт китә.

Аннан соң мин китапта үземә аңлашылмаган урыннарны берничә кат укыйм. Аеруча „Кыскача курс" нын IV нче бүлегенең II нче бүлекчәсен укыганда шулай булды. Бу бүлекчәне кат-кат укырга туры килде. Нәтиҗәдә, аны да яхшы гына үзләштердем.

Марксизм-ленинизм таглиматын өйрәнү—ул, тырышканда була торган эш, түземлелек, тырышлык кына кирәк. Аерым бер әсәр өстендә эшләгәндә аңлашылмый диеп теге яки бу әсәрне укудан баш тартмаска, аны каткат укырга кирәк. Тик шул вакытта гына укуга кызыксыну һәм аны нигездә төшенү мөмкин булачак.

Х. Шакиров.

„ЗӘЙ“ КОЛХОЗЫНДА ӘЛМӘТ МТС ының ОТЧЕТЫ

Гомуми җыелышның көн тәртибендә бер генә мәсьәлә,—ди иптәш Хәбибуллин,—МТС ның 1939 нчы елгы эше һәм „Зәй“ колхозы белән ике арадагы договорның үтәлеше турында отчет.

Көн тәртибен раслаганнан соң отчет өчен сүз МТС директоры иптәш Бадыйковка бирелә.

Иптәш Бадыйков сүзне колхоз белән ике арадагы договорның ничек үтәлүеннән башлады.

МТС 1939 нчы елгы производство планын 98,5 процентка үтәгән. Райондагы барлык төр авыл хуҗалыгы эшенең 58 проценты МТС тарафыннан башкарылган. Мусин, Әсәдуллин һәм „Зәй“ колхозында эшли торган Хәйретдинов иптәшләрнең бригадалары үзләренең планнарын арттырып үтәгәннәр. МТС ның күпчелек эше колхозлар тарафыннан яхшы һәм отличного кабул ителгән. МТС хезмәт күрсәткән участкылардан, башка участкыларга караганда мулрак уңыш җыйнап алынган. Ләкин үткән ел план үтәлеше барлык колхозларда да канәгатьләнерлек булмаган.

Барлык эшне йомшак сөрүгә әйләндереп исәпләгәндә, МТС „Зәй“ колхозы буенча договорны нигездә үтәгән. Ә аерым эш төрләре белән алганда договор тулысынча үтәлмәгән. Мәсәлән, МТС договор буенча яз көне 280 гектар урынына 244 гектарга гына сөргән. Ә 200 гектар туңга сөрүне икенче кат сөрү планы бөтенләй үтәлмәгән. Туңга сөрү планы сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да үтәлмәгән.

Иген уңышын күтәрүдә бик әһәмиятле булган бу эшләрнең кем гаебе белән үтәлмәвен тикшереп карыйк. Иптәш Бадыйков: бу эштә МТС бөтенләй гаепсез дип әйтергә теләмим, договорны тулысынча үтәмәгән өчен без гаепле, ди. Ләкин, гаебнең күп өлеше колхозда, аның җитәкчеләрендә дә бар. Колхозда 2 трактор 34 смена эшләми торган. Аның күпчелеге өчен колхоз гаепле. Яз көннәрендә ягу материалларын вакытында китермәгәннәр. Көзге чәчү вактында 2 көн орлык булмый торган. Комбайн саламын вактында җыйнап алмау аркасында туңга сөрүдә читенлек тудырылган. Плугарлар булмаган вакытлар да күп кенә кабатланган.

Иптәш Бадыйковның докладыннан соң фикер алышулар булды.

Колхозның элекке председателе иптәш Гәрәев:

— МТС директоры иптәш Бадыйков, биредә колхоз җитәкчеләрен нык тәнкыйтьләде. Бу бик урынлы. Чөнки без тракторларның нормаль эшләвенә тиешле шартлар булдырмадык. Ләкин тракторларның еш ватылуына, механикларның бик сирәк булуларына без гаепле түгел. Договорда күрсәтелгән 45 гектар көнбагышны уру өчен комбайн бирмәү, бөртекле культураларны урганда биек уруга МТС гаепле түгелмени?

Трактор бригадасы янында иң кирәкле запас частьләр дә булмый. Кечкенә генә нәрсә өчен дә колхоз МТС ка 6—7 километрга ат җибәрә. Кайсы көнне 3 әр тапкыр ат куарга туры килде. Ә иптәш Ногманов Бәдри тракторы аз гына кәҗәләнсә дә, тизрәк үзенең өенә кайтып китү ягын карый иде.

Тракторчы Юсупов үзенең чыгышында бүгенге мәсьәләләргә тукталды.

— Без 1940 нчы елның язгы чәчүгә тулы хәзерлек белән каршылыйбыз. Тракторларга һәм тагылма коралларга ремонтны безнең бригада МТС та беренче булып тәмамлады. Комиссия ремонтның сыйфатын яхшы дип тапты. Ләкин „Зәй“ колхозы тракторчылар өчен тиешле эш шартлары булдыру чарасын күрми әле. Даими рәвештә эшләрлек плугарлар билгеләнмәгән. Вагоннарга капитал ремонт таләп ителә. Ә, алар басуда кар астында яталар әле.

Үткән ел безнең эшне тикшереп вактында акт белән кабул итү булмады. Шуның аркасында эш сыйфатын бозучы кайбер тракторчыларга вактында отпор бирелмәде. Бу җитешсезлекләр кабатланмаска тиеш, ди.

Моннан соң чыгып сөйләүче колхоз председателе Хәбибуллин һәм башка иптәшләр МТС ның яхшы эшләве колхозга нык бәйле икәнен күрсәттеләр.

⁂

Җыелыш МТС ның „Зәй“ колхозындагы эшен канәгатьләнерлек дип тапты. Кимчелекләрне күрсәтү белән, аны бетерү буенча конкрет чаралар билгеләп карар кабул итте.

Ләкин шунысы гаҗәп, колхозның 7 бригадирыннан (кырчылык бригадалар) МТС отчеты буенча берсе дә чыгып сөйләмәде. Алар, 1940 нчы ел өчен төзеләчәк торган договорны тикшерүдә дә актив катнашмадылар. Чыгып сөйләүчеләр дә күпчелек эшнең МТС тарафыннан договорда күрсәтелгән срокларда үтәлмәвен тәнкыйтьләмәделәр.

Үткән ел „Зәй“ колхозы бөртекле культуралар уңышын гектарыннан бары 4,6 центнер гына җыйнап алды.

Аның сәбәбе шунда: үткән ел колхоз язгы чәчүгә начар хәзерләнде. Кышкы агротехника чараларын һәм игеннәрне тәрбияләүне тиешенчә үткәрмәде. Ә МТС колхоз эшенә ныклы контроль булдырмады. Кырчылык бригадалары белән трактор бригадалары югары иген уңышы өчен бердәм хәрәкәт итмәделәр. МТС язгы сөрүне һәм бөртекле культуралар чәчүне 17—19 көнгә сузды. Ә колхоз үз көче белән эшләгән участкыны аннан да артык сузды. Кызганычка каршы, колхозда язга хәзерлек быел да канәгатьләнерлек түгел әле.

МТС быел да чәчүгә начар хәзерләнә. Кырчылык бригадалары белән трактор бригадалары арасында бердәм хәрәкәт оештыру эше начар тора. МТС 1940 нчы елның договорында яз көне бөртекле культуралар чәчү срогын 11 көн итеп ала. Ә колхозлар социалистик ярыш договоры буенча бөртекле культуралар чәчү срогын 6—7 көн итеп билгеләделәр. МТС үзе куйган срокларны янадан карап чыкмасмы икән?

З. Салахетдинов.

ЯҢАЛЫККА КИН ЮЛ!

1940 нчы елның язы килә. Без, улым Федор белән икәүләп, кышкы шартларда бик яхшы эшләү өчен алган йөкләмәләребезне тулы үтәдек һәм бу безгә шатлыклы.

Үткән елның җәеннән бирле улым белән бергә СУ—213—39 нчы номерлы паровозда эшлибез. Эшли башлаганның беренче көнендә үк, машинаның бөтен эчке мөмкинлекләреннән тулы файдалану һәм аның детальләренең озакка чыдаулары өчен йөкләмә алдык.

Казан—паровозның йөрәге булып исәпләнә. Промывка ремонтыннан соң паровоз казанын суытырга, ә аннары аңа ягарга кирәк була иде. Ләкин болай эшләгәндә металл тиз бозыла, ут һәм төтен трубаларыннан су ага. Без бер промывкадан икенче промывкага кадәр йөрүне арттырдык. Шуның белән без казанны бозылудан саклауга һәм депода паровозның аз торуына ирештек. Бер промывкадан икенче промывкага кадәр паровозның йөрешен башта 15 мең километрдан 20 мең километрга кадәр җиткердек, аннары 30 мең километрга кадәр һәм соңгы вакытта 45 мең километрга кадәр җиткердек.

Бу саннар артында ныклы көрәш ята. Ике улым: Федор һәм Михаил белән, тимер юл транспортына яңалык кертүчеләрдән Кривонос, Огнев, Яблонский һәм башкаларның тәҗрибәләрен өйрәнү өчен китап укып төннәр буе утырган чаклар күп булды. Инженер иптәш Афанасьев ярдәме белән, без казанга юшкын утыртмау һәм поезд барганда казанны чистарту методын үзләштердек. Минем үземә тимер юл лабораториясендә бик еш булырга туры килде. Казандагы суның анализын белү теләге белән мин лаборантларның эш тәҗрибәләре белән таныштым, алар белән беседалар үткәрдем. Мине химия нык кызыксындырды. 3 айдан соң мин казандагы суның режимы турында депода лекция укуга ирештем.

Депо администрациясе безнең башлангыч уңышларыбызга элек ышанычсыз карады. 38 мең километр йөргәннән соң машинаны смотр өчен туктатырга куштылар һәм көтелмәгәндә, безнең рөхсәтебездән тыш, казанның түбәнге люкларын ачалар. Нәтиҗәдә, бөтенесенең дә үз тәртибендә булуы беленә. Шуңа карамастан, депо администрациясе эшебезне тагын да дәвам иттерергә рөхсәт бирмәде. Шуннан соң без Лазарь Моисеевич Кагановичка иптәшкә мөраҗәгать итәргә мәҗбүр булдык. Сөекле нарком 13 нче февральдә махсус телеграмма җибәрде һәм шул көннән алып без мактаулы эшебезне тагын да дәвам иттерә башладык.

Хәзерге көндә ял итәм. Минем урнымда тәҗрибәле машинист Иютин эшли. Улым Федор үз паровозы белән юл йөреп кайтканнан соң һәр вакыт яныма килә. Без аның белән киләчәктәге эшләр турында план төзибез. Менә тиздән машина обточкага (тәгәрмәчләрнең бандажларын алмаштырырга) туктаячак. Моннан соң икенче обточкага кадәр бөтенләй промывка ремонты ясамаска уйлыйбыз. Транспорт әлегә кадәр мондый рекордны белми.

Хезмәткә намус белән карагач хезмәт хакы да арткаңнан-арта бара. Бездә машинист айга 1.800—2.000 сум, аның ярдәмчесе 1.000 сум, кочегар 600—700 сум хезмәт хакы ала.

Соңгы вакытта депода папавинчылар саны арта. Машинистлардан Шкатов, Веригин, Парыгин, Волгушев иптәшләр зур уңышларга ирештеләр. Карманников һәм Кунгуров иптәшләр үзләренең паровозлары белән көн саен 230 километр урнына 700 километрга кадәр юл йөриләр.

Мондый нәтиҗәләрне күрүе зур шатлык, әлбәттә. Без аерым иптәшләрнең рекордларыннан бөтен коллектив белән удар эшкә күчәргә тиешбез. Шул чагында Әгерже депосы бөтен Казан тимер юлы буенча беренчелекне алыр.

М. Захаров.

Әгерже депосы машинисты.



4 нче тегү фабрикасының стахановчыларыннан (сулдан уңга) Т. В. Кирсанова, М. Әхмәтҗанова һәм С. Җәлалова иптәшләр. Алар Татарстанның XX еллыгына хәзерлек уңае белән алган йөкләмәләрен арттырып үтиләр.
И. Галиев фотосы.

Чит илләрдә

ФИННӘРНЕҢ КАПИТУЛЯЦИЯ ЯСАУЛАРЫНЫҢ СӘБӘПЛӘРЕ ТУРЫНДА „НАХТАУСГАБЕ“

БЕРЛИН, 17 март. (ТАСС). „Нахтаусгабе“ нын Стокгольмдәге хәбәрчесенең язуына караганда, Швеция газеталары Финляндиянең көрәшне ни өчен туктатуы турындагы мәсьәләне тикшерәләр. Хәбәрчесенең язуына караганда, Маннергейм линиясенең соңгы ныгытмаларына [illegible] һәм шуннан соң артык оборона линияләренең булмаганлыгын [illegible] беренче тапкыр икрар иткәннәр. Шулай ук руслар артиллериясе финнәрнеке карагандә шул кадәр өстен ки, артык бер нинди ярдәм көтәргә мөмкинлек калмады, чөнки ярдәм барыбер соңга калган булыр иде дип күрсәтелә. Болардан тыш руслар Выборгтан көнбатышта флангта [illegible] позиция булдырганнар. [illegible] Финляндия [illegible] Америка [illegible] (ТАСС).

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 19 март. Кичә фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмау турында рәсми рәвештә хәбәр ителә.

БЕРЛИН, 19 март. Германия армиясенең верховный командованиесе хәбәр итә: „Мозель белән Пфальц урманы арасында — разведчиклар хәрәкәте һәм артиллериядән атышу. Дошманның 2 узар отрядының атакасы кире кагылды.

БЕРЛИН, 18 март. Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, фронтның бер участкасында артиллериядән 2 мең тапкыр атылган. [illegible] 5 кешесе үтерелгәннән соң чигенергә мәҗбүр булган, 8 кеше әсир алынган.

Балтыйк диңгезе өстендә сынау очышы вакытында Германия самолеты ялгыш ориентировка ясаганда 17 нче мартта 12 сәгатьтә Даниянең Лоланд атавында җиргә төшәргә мәҗбүр булган.

[illegible] 17 нче мартта чит илләрнең 2 самолеты күренгән. Швейцариянең зенит артиллериясе аларга каршы ут ачкан, ә истребительләр аларны эзәрлекләгәннәр. Самолетлар көнчыгышка таба очып киткәннәр.

ЛОНДОН, 18 март. Авиация министрлеге хәбәр итүенә караганда, кичә Англия самолетлары Гельголанд буктасы районында Германиянең берничә патруль карабына бомбалар ташлаганнар. Карабларның берсендә янгын чыккан.

НЬЮ-ЙОРК, 19 март. Европада сугыш башланганнан бирле сугышучы илләр Американың 128 пароходын тотканнар. Шуларның 108 пароходы Англия властьлары, 16 пароходы Франция һәм 4 пароходы Германия властьлары тарафыннан тотканнар.

Венесуэланың төньяк ярлары янында [illegible] Германия пароходы [illegible].

Ассошиэйтед Пресснын хәбәр итүенә караганда, англичаннар Нью-Йорк портындагы „Куин-Мэри“ һәм „Мавритания“ исемле зур пароходларны Австралиядән гаскәрләр ташу өчен файдаланырга уйлыйлар.

ТОКИО, 19 март. Сингапурдагы Англия властьлары Японияннән Европага бара торган „Фусими-Мару“ пароходын тотып, аннан почта конфискация иткәннәр.

ЛОНДОН, 19 март. „Франциядән 3.137 тонна авырлыгындагы „Капитан Августин“ пароходы Англиянең көнчыгыш ярлары янында минага бәрелеп баткан. Команданың 2 кешесе үлгән, калганнары коткарылганнар.

ЛОНДОН, 18 март. 5.225 тонна авырлыгындагы „Тайбертон“ пароходы [illegible].

БРЮССЕЛЬ, 18 март. Сугыш башланганнан бирле Голландиянең диңгез флотының югалтулары [illegible] 15 процент. Голландия барлыгы 95 мең тонна авырлыгындагы 21 корабын югалткан.

(ТАСС).

ТАЛЛИНДА СОВЕТ ИЛЧЕЛЕГЕНДӘ КАБУЛ ИТУ

ТАЛЛИН, 19 март. (ТАСС). Кичә СССР ның Эстониядәге илчесе иптәш Никитин кабул итү ясады. Кабул итүдә Эстониянең баш министры Улуотс, чит ил эшләре министры Пийп, Эстония армиясенең баш командующие Лайдонер, Эстония хөкүмәте членнары һәм [illegible] катнаштылар. Мәҗлес дуслык шартларында барды һәм 3 сәгатьтән артыграк дәвам итте.

ФРАНЦИЯДӘ ХӨКҮМӘТ КРИЗИСЫ ТУРЫНДА РЕЙТЕР АГЕНТЛЫГЫ

ЛОНДОН, 19 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Париждагы хәбәрчесенең хәбәр итүенә караганда, Франция радиосы Франция кабинетын үзгәртеп корунын котылгысыз дип саналуы турында хәбәр иткән.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

КӨНЬЯК КЫТАЙДА. Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә Наньнин—Циньчжоу шоссе юлыннан көнчыгыштарак каты сугышлар дәвам итә. Японнар Гуанси һәм Гуандун провинцияләре чигендәге Линшаньны алырга маташалар. Японнарның бу секторда хәрәкәт итүче 3 колоннасы акрынлап алга таба бара. Кытай гаскәрләре аларга ныклы каршылык күрсәтәләр.

Гуандун провинциясенең төньяк-көнчыгыш өлешендә кытай гаскәрләре Сватоудан төньяктарак һөҗүм алып баралар.

ҮЗӘК КЫТАЙДА. Японнарның мең кешелек отряды Чжэцзян провинциясендә Уканнан төньяктарак районда кытайларның позицияләренә атака ясады. Йөзләп кешеләре үтерелгәннән һәм яраланганнан соң японнар чигенделәр.

16 нчы мартта төнлә кытай партизаннары Хунань провинциясендә, Иочжоу районында шоссе юлын берничә урыннан җимерделәр, бер тимер юл күперен һәм бер шоссе юлы күперен шартлаттылар.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА. Шаньси провинциясендә японнарның Тайюаньнән көньякка таба башлаган һөҗүмнәре уңышсыз чыкты. Кытай гаскәрләре үзләренең барлык позицияләрен кулларында нык тоталар.

19 март. (ТАСС).

Мәктәпләрдә сынауларның яңа тәртибе

РСФСР мәктәпләре алдагы тикшерү һәм чыгару сынауларына хәзерләнәләр.

Үткән елгыдан аермалы буларак, быел башлангыч, тулы булмаган урта һәм урта мәктәпләрнең барлык классларында телдән булачак сынаулар билетлар буенча үткәреләчәк. Билетларны укытучылар төзи һәм аларга уку программасының төрле бүлекләреннән укучыларның аңлавы өчен ачык булган 2—3 сорау кертелә. Кирәк чакларда, әгәр укучылар алган билетлары буенча җавап бирергә кыенсынсалар, укытучы укучыларның чын белемнәрен белү өчен өстәмә сораулар бирә ала.

Тикшерү һәм чыгару сынауларының саны киметелә. VII нче классларда 11 сынау урнына 8 сынау билгеләнә (моннан элек хәбәр ителгәнчә 6 түгел). Боларның 6 сы телдән, 2 се язма рәвештә үткәрелә. X нчы классларда 12 сынау урнына 11 сынау үткәреләчәк: 8 е телдән һәм 3 се язма рәвештә.

Укучыларның начар билгеләр алган дәресләре буенча өстәмә сынаулар шул класста төп сынаулар тәмам булганнан соң үткәрелә. (ТАСС).

ҖИТӘКЧЕЛЕК ИТМИЛӘР

Әлмәт районының күпчелек авылларында укый-яза белмәүчелекне бетерү эше начар оештырылган. Райондагы 1.560 укый-яза белмәүчедән 835 кеше һәм 2.054 аз укый-яза белүчедән бары 838 кеше генә укуга тартылган.

Колшәрип авыл советында (председателе иптәш Саттаров) аз укый-яза белүчеләрне укыту бөтенләй оештырылмаган, укый-яза белмәүчеләрнең дә 30 проценты гына укый. Бу авылда бер генә укытучы да зурларны укыту белән шөгыльләнми. Кама авылында да шундый ук хәл. Биредә зурлар мәктәбе өчен кайтарылган дәфтәрләрне башкаларга сатып, зурлар мәктәбендә укучыларны бөтенләй дәфтәрсез калдырдылар. Миңлебай авыл советында (председателе иптәш Каюмов) зурларны укыту бөтенләй оештырылмаган. (ТатТАСС)

БАШЛАНГЫЧ ПАРТОЕШМА СЕКРЕТАРЬЛАРЫ ӨЧЕН СЕМИНАРЛАР

ВКП(б) ның Әгерже райкомы башлангыч партоешмаларның яңа сайланган секретарьлары һәм аларның урынбасарлары өчен 3 көнлек семинар үткәрде. Семинарда 30 кеше катнашты. Алар партия хуҗалыгын алып бару турында, партия пропагандасының куелышы турында, партия җыелышларын оештыру турында инструктаж алдылар һәм халыкара хәл турында доклад тыңладылар.

БҮГЕНГЕ ТӨРКИЯ

Күптән түгел генә Төркия бәйсез ил иде. Аның эчке һәм тышкы политикасы Ататөрек тарафыннан нигезләре корылган дәүләтнең интереслары белән билгеләнә иде. 1920—22 нче елларда Төркияне кол итәргә омтылган Англия—Франция интервентларын тар-мар итүне Ататөрек оештырган иде. Госман империясенең җимерекләре өстендә Ататөрек җитәкчелегендәге дәүләт төзелде. Балканда һәм Якын Көнчыгышта тынычлыкны саклау, үзенең күршеләре белән дуслык мөнасәбәтләрен ныгыту бу дәүләтнең төп принципларыннан берсе иде. Бу политика төрек халкына яхшы нәтиҗәләр бирде һәм ул илнең халык хуҗалыгы үсешенең темпларында күренде.

Хәзер хәл үзгәрде. Англиянең—Франциянең сугыш уты кабызучылары Төркияне үз арбаларына җигә алган вакыттан бирле төрек халкы киләчәкне торган саен куркынычлырак итеп күрә.

Мәгълүм ки, 1939 нчы елның көзендә Төркия нейтралитет саклау политикасыннан баш тарту юлына басты һәм Англия белән, Франция белән үзара ярдәмләшү турында килешү ясады. Бу килешү буенча Төркиянең дә алар ягыннан сугыш хәрәкәтләренә тартылуы мөмкин. Бу рольне үтәүгә хәзерлек Төркиягә зур зарар да китерә башлады. Илнең сугышка уңайланып, ашыгыч рәвештә яңа баштан корыла торган экономикасы зур кыенлыклар кичерә. Англия һәм Франция тарафыннан диңгез юлларында оештырылган блокада да Төркиянең халык хуҗалыгының хәленә зур гына йогынты ясый. Төркиянең тышкы сәүдәсе кими. Төркия портлары торгынлык кичерәләр.

Төркиянең 1939 нчы елгы тышкы сәүдәсе турында хәзергә тулы саннар юк әле, ләкин 11 айга булган саннар да товар оборотының шактый кимегән булуын күрсәтәләр. Төркиянең тышкы сәүдәсе турындагы түбәндәге таблицадан бу ачык күренә.

	Экспорт	Импорт
1938 ел (11 ай)	126 миллион лира	138 миллион лира.
1939 ел (11 ай)	115 миллион лира	112 миллион лира.
Киму:	11 миллион лира	26 миллион лира.

1939 нчы елның, Европа сугышы шартларында үткән соңгы өч ае эчендә Төркиянең тышкы сәүдәсенең киму темпы уртача еллык киму темпын шактый узып китә.

Төркиянең иң зур клиенты булган Германия белән элгәреге сәүдәсе бөтен тышкы сәүдә оборотының яртысыннан артыграк кына туры килә иде. Хәзер аның белән сәүдә нык кими башлады. 31 нче августта Германия белән Төркия арасында сәүдә килешүенең срогы тулды. Төркиянең яңа юнәлеш алуы сәбәпле бу килешү тулы күләмдә яңартылмады. Күптән түгел Германия белән төзелгән килешү 7,5 миллион лира күләмендә товар оборотын күздә тота. Димәк, Төркия—Германия сәүдәсенең элекке күләменнән күп тапкырлар кимрәк. Шул ук вакытта Англия һәм Франция дә Төркия белән Германия арасындагы сәүдә килешүенең сәүдә обороты өлкәсеннән төшеп калуын капларлык дәрәҗәдә Төркиядән товарлар сатып алуны һәм сатуны арттырырга ашыкмыйлар. Англиянең Төркиягә импорты 1938 нче елга 16 миллион лирадан 1939 нчы елны 6,8 миллион лирага кадәр кимеде.

Төркия базарларында Германия товарларының җитешмәве сизелә. Бу хәл хәзергә кадәр Германиядән җиһазлар һәм запас частьләр белән тәэмин ителеп килгән Төркия промышленностена бик начар йогынты ясый. Төркия матбугаты, Истамбулдагы текстиль фабрикаларының запас частьләр җитешмәү аркасында зур кыенлыклар кичерүләрен яза. „Тан“ газетасы, Төркиядә инде трикотаж әйберләр эшләнми һәм шуңа күрә алар тиздән базарда да булмаслар дип паникага бирелү тонында белдерде.

Ләкин промышленностьтагы кыенлыклар запас частьләр җитешмәве белән генә чикләнмиләр. Машина мае да җитешми. Нефть һәм бензин җитешми. Промышленность чималының күп төрләре җитешми. Мәсәлән, Истамбулдагы консерв фабрикалары, калай булмаганлыктан, консерв эшләп чыгаруны бөтенләй диярлек туктаттылар. Төркиянең үзендә аз күләмдә чыгарыла торган ташкүмернең бәясе нык күтәрелде. Сугышка кадәр күмернең тоннасы 15—16 лира тора иде, ә декабрь аенда 26—28 лирага җитте. Төзү материалларының бәяләре күтәрелде. Төркиядә промышленность төзелеше дә, торак төзелеше дә кими. Мәсәлән, Әнкарәдә парламентның яңа бинасын төзү тукталган.

Күп кенә предприятиеләрнең ябылуы, эшли торган предприятиеләрдә эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең саны киму уңае белән эшсезлек үсә, халыкның мохтаҗлыгы арта. Бу хәлдән файдаланып, хуҗалар, эшчеләрне урыннан чыгару белән куркытып, икешәр смена эшләргә мәҗбүр итәләр. Болар барсы да хезмәт ияләрендә зур ризасызлык тудыралар.

Илдә иң әһәмиятле куллану әйберләренең җитешмәве бик нык сизелә. Продуктлар һәм промышленность товарлары бәясе күтәрелә. Европа сугышының беренче көннәреннән үк башланган спекуляция көчәя. Товарлар яшерелә, ә аларның бәяләре тиз күтәрелә башлады. Аннан башка да бик түбән хезмәт хакы алып килгән хезмәт иясе халык гадәттән тыш авыр хәлгә төште. Эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең реаль хезмәт хаклары бик нык кимеде. Төркия матбугаты битләрендә спекуляциягә һәм кыйммәтчелеккә каршы көрәш кирәклеге турында мәкаләләр һәм заметкалар торган саен ешрак чыга. Язучы хатын Саут Дәрвиш „Хәбәр“ газетасының 8 нче январь номерында кин куллану әйберләренең югары бәяләре хезмәт ияләренең хезмәт хакларына һичбер хәлдә дә туры килмәвен күрсәтә торган саннар китерде. Мәсәлән, көздән алып, май бәясе 20—25 процентка күтәрелгән. Башка продуктлар белән дә эш шулай тора.

Күптән түгел генә Истамбулда, товарларны 1939 нчы елның 31 нче августындагы бәяләрдән югары бәя белән сатучы сәүдә предприятиеләре ябылачак, дип игълан ителде. Ләкин, билгеле, мондый чаралар тормышка ашырыла алмыйлар, чөнки шәһәрдәге барлык магазиннарны диярлек ябарга туры килер иде. Хөкүмәт спекулянтларны 500 дән 20.000 лирага кадәр штрафка тарту турында закон чыгарды. Шулай ук спекуляция өчен уголовный җәзалар да күздә тотыла. Законнар чыгарылды, ябыштырылды, ә спекулянтлар яшиләр һәм кысрыклаудан зарланмыйлар.

Гомуми экономик шартлар начарлану белән финанс кыенлыклары торган саен ачыграк күренәләр. Күптән түгел Төркия Англиядән һәм Франциядән 43,5 миллион фунт стерлинг заем алды. Ләкин заемның төп өлеше коралланy кирәкләренә билгеләнгән, ә бу, билгеле, халык хуҗалыгына җиңеллек китермәячәк. Яңа гына кабул ителгән закон буенча Төркия хөкүмәте бөтен халык хуҗалыгын, беренче чиратта транспортны һәм промышленностьны сугыш кирәк-яраклары эшләү юлына күчерә ала. Хөкүмәткә хуҗалык өлкәсендә асылда диктаторлык хокуклары бирелде. Дәүләтнең хәрби контроленнән читтә калырга уйлаучы хуҗаларга карата уголовный җәзалар кулланылачак. Бу чара илнең җитештерү көчләрен тагын да ныграк богаулый.

Англия һәм Франция белән үзара ярдәмләшү турындагы договор Төркиягә менә нәрсә китерде. Ләкин бу әле чәчәкләре генә, җимешләре—киләчәктә. Англия—Франция сугыш блогы үзенең союзнигыннан договор йөкләмәләрен үтәүне таләп иткәч, алар тулы килеш ачылырлар.

П. ПЕТРОВ.

ВРАЧЛАРНЫҢ БЕЛЕМЕН КҮТӘРҮ ИНСТИТУТЫНЫҢ XX ЕЛЛЫГЫ

Казанда врачларның белемен күтәрү буенча В. И. Ленин исемендәге институт шушы елның июнь аенда үзенең XX еллык юбилеен үткәрә.

Институтның профессорлары, укытучылары һәм башка работниклары юбилейне лаеклы рәвештә үткәрүгә хәзерләнәләр. Институтның эше турында Казанның зур предприятиеләрендә, Кызыл Армия частьләрендә һәм районнарда докладлар үткәреләчәк. Радио аркылы да күп кенә докладлар, лекцияләр тапшырылачак.

Институтның терапевтика факультеты деканы профессор Русецкий институтның эше турында болай ди:

— Институт 20 ел эчендә 11.356 врач укытып чыгарды. Алар Казанда, Татарстан районнарында, кардәш республикаларда һәм СССР ның башка өлкәләрендә эшлиләр. Шул ук чорда институтта 40 профессор, 70 доцент, 306 ассистент хәзерләнде. Безнең профессорлар Москва, Казан, Сталинград, Свердловски һәм башка шәһәрләрдәге ВУЗ ларда укыталар, клиникаларда эшлиләр.

Институтның фәнни работниклары 2.647 фәнни хезмәт язып чыгардылар. Бу хезмәтләрнең кайберләре китап булып басылды, журналларда, җыентыкларда урнаштырылды.

Институтның клиникалары һәм поликлиникалары хезмәт ияләренә медицина ярдәме күрсәтү эшендә бик зур урын тоталар. Аның учреждениеләрендә 10 урында физиотерапия, 12 урында рентгенология кабинетлары һәм 17 лаборатория бар. Авырулар кабинетларда электр яктылык, су, рентген, ради һәм башка төрле методлар белән дәваланалар.

20 ел эчендә институтның клиникаларындагы койкаларда 156 меңнән артык кеше дәваланды. Поликлиникалар һәм амбулаторияләр аркылы 1 миллион 752 мең кеше үткәрелде. Физиотерапия кабинетларында 1 миллион 221 мең процедура, рентген кабинетларында 221 мең, ради белән дәвалау буенча 10.266 процедура ясалды. 2.095 кешегә кан күчерү үткәрелде. 55 мең кешегә операция ясалды.

Соңгы вакытта институтның клиникаларында нервы, йөрәк ауруларын, шулай ук башка күп төрле авыруларны иң соңгы методлар буенча тикшерү һәм дәвалау эшләре алып барыла. Хәзерге көндә институтның хирургия, терапевтика, акушерлык, күз авырулары, гинекология, травмотология, балалар авырулары клиникалары һәм башкалар эшли. Иститутның 26 кафедрасы бар. Соңгы вакытта оборона дисциплиналары кафедрасы да оештырылды.

Институтның XX еллыгын үткәрү өчен Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы председателе урынбасары иптәш Сөләйманов председательлегендә хөкүмәт комиссиясе төзелде. Юбилей көннәренә медицинаның төрле тармаклары буенча институтның фәнни хезмәтләре басылып чыгачак.

Г. Латыйпов.

ФӘН РАБОТНИКЛАРЫНЫҢ КОЛХОЗЛАРГА ЯРДӘМЕ

Академик Вильямс исемендәге туфрак-агрономия станциясе һәм Тимирязев исемендәге Авыл Хуҗалыгы Академиясенең туфракны өйрәнү кафедрасы работниклары коллективлары авыл хуҗалыгы ВУЗ лары, техникумнарының, фәнни тикшеренү институтларының һәм тәҗрибә станцияләренең работникларын колхоз производствосына фәнни [illegible] конкрет ярдәм күрсәтүгә чакырып мөрәҗәгать иткәннәр иде. Казан Авыл Хуҗалыгы институтының фәнни работниклары, укытучылары һәм студентлары бу чакыруны котлап каршы алдылар. Шул уңай белән институтның фәнни работниклары Татарстанның Октябрь, Кайбыч, Балык Бистәсе, Мамадыш районнарында барлыгы 24 колхозда булып кайттылар.

Институтның кафедралары бу колхозларда агротехника чараларын үткәрү эшен тиешле югарылыкка күтәрүне, колхозларның һәр гектардан 100 пот иген уңышы алуларына практик ярдәм күрсәтүне үзләренә бурыч итеп куйдылар. Дүртенче курс студентларының 20 нче марттан 1 нче сентябрьгә кадәр үткәрелә торган производство практикалары да шул чараларны тормышка ашыру өчен [illegible]. Татарстанда югары иген уңышы алу өчен яңа агротехник чаралар [illegible] культураларга кертү һ. б. өстендә практик эш алып барылачак.

ТАТРЫБТРЕСТ ҺӘМ АНЫҢ ЗАВОДЛАРЫ ТУРЫНДА

Партиябезнең тарихи XVIII нче съезды балык промышленносте работниклары алдына конкрет бурычлар куйды. Ләкин Татрыбтрест һәм аның заводлары бу мактаулы һәм җаваплы бурычларны үтәү өчен көрәшне тиешенчә оештыра алганнары юк. Трест управляющие Ворожецов, партоешма секретаре Макеев иптәшләр кәгазьләр волокитасы эченә кереп чумганнар. Алар заводларда эшнең чын торышын үзләре дә ачык белмиләр, эштә хөкем сөргән тирән өзеклекнең сәбәпләрен өйрәнмиләр. Трест буенча үткән елда балык тоту буенча дәүләт планының 69,3 процентка гына үтәлүе моның ачык күрсәткече.

Бу кимчелекләр быел да кабатлана әле. Моның шулай икәнлеген Чистай заводы (директоры иптәш Стрелов) мисалендә генә дә ачык күрә алабыз. Билгеләнгән планны тулы үтәү өчен бөтен мөмкинлекләр булуга да карамастан, бу завод январь һәм февраль айлары планын 69,5 процентка гына үтәгән. Районның Ленин исемендәге колхозында балык тоту бригадасы (бригадиры иптәш Зубков) эшкә бөтенләй керешмәгән дә әле. Шулай да, бу аяныч хәл трест һәм завод җитәкчеләрен һич борчымый, алар эшне көлгә салу өчен бармакка-бармак та сугып карамыйлар.

[illegible] якынлаша. Ә язга хәзерлек турында Чистай заводында һичкем кайгыртмый. План буенча ремонтланырга тиеш булган 42 көймәнең бүгенге көнгә берсе дә ремонтланмаган. Балык тотучылар өчен кирәк-яраклар һәм эш киемнәре хәзерләү буенча да практик эш күренми әле. Үзенә 90 кешене берләштергән завод коллективында массовый-политик тәрбия эшләренең торышы һич канәгатьләнерлек түгел. Бу хәл трест управляющие иптәш Ворожецовка күптән билгеле булса да, ул кимчелекләр алдында югалып калган. Трест заводлар эше белән кабинеттан торып кына „җитәкчелек" итүен, сводкалар җыю белән генә чикләнүен хәзергәчә дәвам иттерә.

Бу яраксыз практика якын арада бетерелергә, балык тоту буенча дәүләт планын үтәү өчен барлык чаралар күрелергә тиеш.

К. Исламов.

Финпланны арттырып үтәү өчен

Кызыл Юл районы финанс работниклары арасында республикабызның XX еллыгы хөрмәтенә социалистик ярыш торган саен киңәя бара. Хәзер район финанс туплау планын үтәү буенча республика күләмендә 5 нче урында тора. Бик күп кенә авыл советлары беренче квартал планын срогыннан элек арттырып үтәделәр.

1939 нчы елда яхшы эшләве өчен район башкарма комитетының һәм район финанс бүлегенең күчмә кызыл байрагы белән бүләкләнгән Иске Тазлар авыл советы беренче квартал планын 20 нче февральдә үк 120,4 процент, Ташкичү авыл советы 100 процент итеп үтәделәр. Иске Тазлар авыл советы председателе иптәш Галимҗанова финанс активистларының эшләренә якыннан торып ярдәм итә.

Ләкин районда планны үтәмәүче авыл советлары да бар әле. Шекә, Апаз, Түбән Оры, Сәрдәбаш авыл советларында беренче квартал планының үтәлеше һич тә канәгатьләнерлек түгел.

Социалистик ярышны тагын да киңрәк җәелдереп, алдынгы авыл советларының яхшы эш методларын артта калучы авыл советларына күчерербез һәм планның тулысынча үтәлүен тәэмин итәрбез.

Мортазин.

Мәктәпләрдә язгы каникуллар

25 нче марттан алып 31 нче мартка кадәр башлангыч һәм урта мәктәпләрдә язгы каникуллар үткәрелә.

Каникуллар вактында укучылар һәм балалар өчен театрларда һәм клубларда спектакль-концертлар биреләчәк. Казан кино-театрлары балалар өчен һәр көн икешәр сеанс оештырачаклар.

18 нче марттан алып 30 нчы мартка кадәр шәһәрнең барлык районнарында балалар [illegible] Пионерлар йортында Татарстан Верховный Советы депутатлары белән пионерларның очрашу кичәсе булачак.

25—29 нчы мартта Казанда 12 шәһәрнең [illegible] гимнастика ярышлары үткәрелә. 24 нче мартта укучыларның шәһәр күләмендә шахмат турниры башлана.

Каникуллар вактында уку отличникларыннан 40 кеше Москвага экскурсиягә җибәрелә. Отличник укучылар өчен шулай ук Васильевога, Зеленодольски шәһәренә һәм Бирюли җәнлек совхозына экскурсияләр оештырылачак.

Яш тамашачылар театрында укучылар [illegible] Татар Дәүләт Академия театры да балалар өчен спектакльләр оештыралар.

Кино

„ШӘХСИ ЭШ" *)

Балаларны коммунистик рухта тәрбияләү эшен көчәйтү—иң мөһим бурычларның берсе булып тора. Бу бурычны үтәү өстендә совет җәмагатчелеге, комсомол һәм пионер оешмалары, мәктәпләр һәм ата-аналар, театр һәм кино җидди рәвештә эшләргә тиешләр.

Хәзер Казан экраннарында күрсәтелә торган „Шәхси эш" исемендәге яңа кинофильм нак менә шушы мәсьәләнең бер тармагына—балалар арасында иптәшлек, дуслык мәсьәләсенә, шәхси эшне коллектив эш белән бәйли белүгә багышланган.

Вакыйга Волга буендагы бер шәһәрнең урта мәктәбендә бара. Мәктәпнең 6 нчы классында укучы Аркадий Зубовны микроскопның иң кыйммәтле кисәген—окулярны урлауда гаеплиләр, чөнки окуляр аның портфеленнән табыла. Зубов үзенең портфеленә окулярны кем салганын яхшы белә. Ләкин аны әйтми. „Мин иптәшләр өстеннән „әләкләргә" тиеш түгелмен" дигән фикердә тора. Класс аның пионерларча әйтүенә ышанмый, дәлилләр таләп итә.

Аркадийны шушы хәлгә төшерүче укучы Лева Прокушев үзенең гаебен ачарга куркып йөри. Ул үзенең иптәше Витя Суриков белән бер вакыт микроскопны ватып, окулярны үз кесәсенә сала, ә укытучы тикшерә башлагач, һичбер начар нәрсә уйламыйча, окулярны Аркадий портфеленә сала. Бик күп вакыт буена уйланып йөргәннән соң гына, ул, эшнең ничек булуын сөйләп бирергә кыючылык итә һәм шуның белән, Аркадийны зур бәладән коткара. Аның иптәше Суриков та Аркадийның гаепсез булуы турында анонимный хат сала.

Картина иптәшлекне, дуслыкны ничек белү кирәклеген өйрәтә. Димәк, бөтен коллективка кагылган мәсьәләне үзеннең „шәхси эшең" итеп карау, „мин иптәшләр өстеннән әләкләргә тиеш түгел" дип, дөреслекне коллектив алдында ачмау—ул зур ялгышлык.

Картина бик җидди итеп эшләнгән. Ул тамашачыны беренче кадрлардан ук кызыксындыра, ышандыра һәм бик яхшы тәэсир калдыра. Кайбер яшь артистларның әле үзләренә ышанмыйчарак уйнаулары бу тәэсирне һич киметми. Арада бик матур уйнаучы яшьләр барлыгын да әйтергә кирәк. Аркадийның энесе Геня ролен уйнаучы Петя Гроховский, Лидочка ролен уйнаучы Дагмара Дерингер, Витя Суриков ролен уйнаучы Лева Мирский, аеруча сөйкемле уйныйлар. „Гармонь", „Чуртан кушуы буенча" һәм башка кайбер картиналарда баш рольләрне уйнаган Савин бирелә дә укытучы Владимир Николаевич ролен гаят оста башкара.

Г. Беляев.

*) Союздетфильм. Режиссер Александр Разумный постановкасы. В. Поташов сценариясе.

КАЗАН ШӘҺӘРЕ БЮДЖЕТЫ

1940 нчы елга Казан шәһәре бюджеты 67 миллион сум күләмендә расланды.

Халык мәгарифе эшләренә 25 миллион сум, сәламәтлек саклауга 23 миллион 200 мең сум, коммуналь хуҗалык эшләренә 13 миллион 100 мең сум тотылачак. Быел [illegible] өчен яңа мәктәп төзелә. Ленин районындагы мәктәпне төзү тәмамлана. Бауман районында 24 квартиралы яңа йорт салу өчен 750 мең сум билгеләнде. Укытучылар өчен Галактионов урамында салына торган йортны төзү тәмамланачак. Шәһәр больницаларын реконструкцияләүгә 1 миллион 600 мең сум билгеләнде.

СУДНОЛАРГА РЕМОНТ ЯСАУ АЛДЫНГЫЛАРЫ

Чистай затонында кышлаган „Красное Сормово" дигән буксир пароходы (капитаны М. Лызин, механигы И. Косолапов) срогыннан элек ремонттан чыгарылган иде. Ремонт югары сыйфатлы итеп үткәрелде. Шуның өчен бу пароход Елга Флоты Халык Комиссариатының вымпелын һәм премиясен алуга кандидатлар исемлегенә кертелде. Команда бу пароходка ремонтны үз көче белән үткәрде. Регистр уполномоченные ремонтны отлично үткәрелгән дип тапты.

Чаңгы спорты сезоны ябылу уңае белән Займищеда зур ярышлар үткәрелде. 10 километрга ирләр командалары өчен булган эстафетада беренче урынны „Спартак" командасы яулап алды. РӘСЕМДӘ: „Спартак" командасы членнарыннан (сулдан уңга) Аксенов, Хрусталев, Фәсхи һәм Ермаков иптәшләр.

В. Лаврентьев фотосы.

18 нче мартта, чаңгы спорты сезоны ябылуга багышлап үткәрелгән ярышларда хатын-кызлар командалары өчен булган эстафетада беренче урынны „Медик" җәмгыяте командасы алды. РӘСЕМДӘ: „Медик" командасы членнарыннан (уңнан сулга) Харитонова, Хлопушина, Захарова һәм Кормильцева иптәшләр.

В. Лаврентьев фотосы.

ШТАНГИСТЛАР ЯРЫШЫ

СССР штангистлары (авырлык күтәрүчеләр) бөтен дөнья күләмендәге бик күп рекордларны үз кулларында тоталар. Киевле Хотимский, Москвалы Божко, Механик һәм башкалар дөньяның иң күренекле спортчыларыннан саналалар. Ләкин, Казан штангистлары, башка зур шәһәрләр белән чагыштырганда, әле бик нык артта калып баралар. Узган ел Казанда СССР беренчелеге өчен үткәрелгән ярышларда катнашучылар арасында Казаннан берәүнең дә булмавы моны бик ачык күрсәтеп тора.

18 нче мартта Казан һәм республика беренчелеге өчен үткәрелгән штанга ярышларында 20 дән артык кеше катнашты. Васильево агач заводыннан килгән 5 иптәшне санамаганда, районнардан бер вәкил дә юк иде. Спортның бу әһәмиятле төре белән районнарда шөгыльләнмиләр һәм республика спорт комитеты бу турыда уйланмый.

Спорт җәмгыятьләреннән „Спартак", „Наука" һәм башкалар, шулай ук, штанга спорты белән бик очраклы гына шөгыльләнәләр. Шунлыктан, һәр ярышларда диярлек, „Динамо" һәм „Крылья Советов" спортчыларына конкурентлар булмый.

Соңгы ярышларда Кучушев һәм Варварин иптәшләр үз өсләрендә бик нык эшләгәнлекләрен күрсәттеләр. Мәсәлән, үз авырлыгы 67 ярым кило булган Хәсән Кучушевның 120 килоны күкрәккә алып аны югарыга күтәрүе, ә 55 кило ярым авырлыгындагы Варваринның—97 кило ярым күтәрүе Казан өчен зур уңыш булып тора. Бу иптәшләр үз өсләрендә эшләүне дәвам иттерсәләр, бик тиз арада СССР мастеры дигән исемне алуга ирешәчәкләр. Динамочы Гомәр Байбеков, „Крылья Советов"тан Морозов һәм Белов иптәшләр дә аларны куып киләләр. 18 нче мартта булган ярышларда бу иптәшләр яхшы күрсәткечләр бирделәр. Ярышларда иң җиңел үлчәүдәгеләр арасында беренче урынны Варварин, җиңел үлчәүлеләр арасында—Кучушев, урта үлчәүдәгеләр арасында—Байбеков, ярым авыр үлчәүдәгеләр арасында—Морозов иптәшләр алдылар.

Республика спорт комитеты апрель аенда бокс ярышлары үткәрергә уйлый.

„Падь серебряная" мәктәп сәхнәсендә

Алабуганың Ленин исемендәге урта мәктәбе укучылары көче белән мәктәп сәхнәсендә „Падь серебряная" пьесасы куелды. Постановка зур уңыш белән үтте. Спектакльне 200 кеше карады.

Шахмат чемпионаты тәмам булды

САЙГИН — КАЗАН ЧЕМПИОНЫ

Казан шахматчыларының быелгы ярышы яшь шахматчы Сайгинның җиңүе белән тәмам булды. Нәҗметтиновтан башка аңа бу турнирда конкурент булмады диерлек. Соңгы турга кадәр аның Нәҗметтиновтан бер очкосы артык иде һәм бу хәл соңгы турда да үзгәрмәде. Ахыргы партияне ничья белән тәмамласа да, аның инде беренче урынга чыгуы тәэмин ителгән иде. Шунлыктан булырга кирәк, Виноградов белән ул бик сакланып уйнады һәм партия тиз арада ничья белән тәмамланды. Нәтиҗәдә, Нәҗметтиновның лидерны куып җитү мөмкинлеге калмады. Аның да Кильматов белән очрашуы ничья белән тәмамланды. Сайгин барлыгы 8 һәм Нәҗметтинов—7 очко җыйдылар.

Өченче урынны алган Хенкин (6 очко) бу турнирда зур күтәренкелек белән уйнады. Соңгы турларның берсендә Сайгинга оттырмаса, ул тагын да югарырак урынны өмет итә ала иде. 18 яшьлек Вельтмандер (5 ярым очко) дүртенче урынны алды һәм киләчәктә гаять көчле шахматчы булачагын күрсәтте. Косолапов, Колчурин, Натариус һәм Щербаков, 4 ярымышар очко җыеп, 5, 6, 7 һәм 8 нче урыннарны бүлештеләр. Ермолин, Кильматов һәм Виноградов 3 ярымышар очко белән 9, 10 һәм 11 нче урыннарны бүлделәр.

Чемпионатның оештырылу ягы начар булганлыкны күрсәтмичә үтеп булмый. Турнирдан соң, Нәҗметтиновның чемпионатта уйналган бер-ике партияне күрсәтүен һәм соңыннан 25 тактада бер юлы уйнау сеансы бирүен санамаганда, турнир тирәсендә бер төрле дә масса эше алып барылмады.

Хэй.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

ТАПТАЛГАННАР. Валентина Таренина дигән 13 яшьлек кыз Куйбышев урамында 1 нче маршрут трамваеннан сикереп төшмәкче булган, ләкин тагылма вагон астына эләгеп тапталып үлгән. Свердлов урамында А. Гурьянов дигән 10 яшьлек малай 4 нче маршрут трамвае баскычына утырып барган вакытта егылып төшкән. Вагон көпчәге аның сул аягын өзеп киткән. Гурьяновны авыр хәлдә больницага озатканнар.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

МӘКТӘПЛӘР ҺӘМ КЛУБЛАР ИГТИБАРЫНА!
„Союзкинопрокат" Татарстан бүлегенең фильмнәр фондында
география, ботаника, зоология, табигат белеме, физика һәм биология уку предметлары буенча мәктәпләрдә һәм түгәрәк занятиеләрендә күргәзмә пособие итеп файдаланыла алырлык
ТАР ПЛЕНКАЛЫ ТАВЫШСЫЗ ФИЛЬМНӘР БАР ҺӘМ ПРОКАТКА БИРЕЛӘ
Фильмнәр „Союзкинопрокат" ның Татарстан бүлегендә (Нариманов урамы, 66; телефон 2—05) гомуми ял көннәреннән башка һәр көн бирелә. Прокат бәясе: мәктәпләрдә бер сеанс күрсәтү өчен 50 тиен.
450—1

„ГЛАВКИНОПРОКАТ" ның ТАТАРСТАН БҮЛЕГЕ
якын көннәрдә Татарстан АССР киноэкраннарына яңа фильмнәр бирә:
1. Мостехфильм кино-студиясендә эшләнгән, художестволы, документаль яңа фильм
АВЫЛДА ЯҢАЛЫК
Сценарий авторы һәм режиссер Виктор Гейман.
Фильм социалистик авыл хуҗалыгында партияле һәм партиясез большевикларның җиңүләре турында сөйли.
2. Мосфильм киностудиясендә эшләнгән художестволы, документаль яңа фильм
20 ЕЛ ЭЧЕНДӘ КИНО
Фильм Совет кинематографиясенең үсеш чорлары, шулай ук Совет һәм чит ил фильмнәреннән художестволы аерым вакыйгаләр бирелә.

Горпромторгның әйберләр сатып алу пунктларында
дәүләт учреждениеләреннән, предприятиеләрдән, кооператив һәм җәмагат оешмаларыннан хәзер акчага
ТӨРЛЕ ӘЙБЕРЛӘР САТЫП АЛЫНА
ӘЙБЕРЛӘР ТҮБӘНДӘГЕ ПУНКТЛАРДА АЛЫНА:
Куйбышев урамы, 7—паласлар, картиналар, язу һәм исәпләү машиналары, мебель, кесә һәм стена сәгатьләре.
Бауман урамы 10 нчы йортта һәм Чернышевский урамында Пассажда—паласлар, картиналар язу һәм исәпләү машиналары, кесә, стена сәгатьләре һәм башка әйберләр.
Ягодный базарында—паласлар, картиналар, кесә һәм стена сәгатьләре һәм башка әйберләр.
479—3—1

Казанда (Кече-Галактионов урамы, 24. Телефон 3—76)
А. М. ГОРЬКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ МУЗЕЙ АЧЫЛДЫ
Музей эш көннәрендә көндез 12 сәгаттән кич 6 га һәм гомуми ял көннәрендә көндез 10 сәгаттән 4 кә кадәр ачык.
Атнаның 1 нче көннәрендә музей эшләми.
510—2—2

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
һәм зур программа буенча
ЦИРК УЕНЫ
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

2—3 КЕШЕ УРНАШЫРЛЫК
БҮЛМӘ КИРӘК
ТҮЛӘҮ КИЛЕШҮ БУЕНЧА
Бауман урамы, 19, Камиль Якуб исемендәге китап фабрикасы адресы буенча яисә 29—09 телефоны буенча, эшбашкаручыга мөраҗәгать итәргә.
518—1

Барлык оешмалар һәм гражданнар игтибарына!
ТАТМЕТРОВЕС
шушы ел 10 нчы марттан башлап, самовар, чәйник, поднос, кровать, велосипед һәм башкалар кебек
йорт әйберләрен никельләү өчен
ЗАКАЗЛАР АЛА
Казан, Киров урамы, 48.
487—1

КИРӘК:
Центроэлектромонтаж трестының Казан конторасына, Казанда һәм башка урыннарга китеп эшләү өчен, ирләрдән һәм хатын - кызлардан — БАРЛЫК РАЗРЯД ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР, ЭЛЕКТРОСЛЕСАРЬЛАР, ПРОИЗВОДСТВОЧЫ БУХГАЛТЕР һәм берәр эш буенча квалификация алырга теләгән ГАДИ ЭШЧЕЛӘР кирәк. Кирәк кешеләргә тулай торакта урын бирелә. Контораның кадрлар бүлегенә килергә. Казан, Банк урамы, 13.
408—5—4

Серго Орджоникидзе исемендәге заводка югары КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ ОБОЙЧЫЛАР һәм СТЕНОГРАФИСТЛАР. Заводның кадрлар бүлегенә килергә.
459—4—2

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
21 нче мартта
ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ
22 нче мартта
ИРЕК
Талоннар белән кертелми.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
21 һәм 22 нче мартта
ЛЕНИН
Талоннар белән кертелми.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, яңа кино-комедия ТАШЛАНДЫК
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ПРЕМЬЕРА ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8 һәм 10 да	Документаль фильм БЕЗНЕҢ КИНО
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	ДУБРОВСКИЙ
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ШӘХСИ ЭШ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник" 6, 8 һәм 10 да.	ПАТРИОТ
„РОТ-ФРОНТ" 6, 8, 10 да.	ПАТРИОТ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП

Сукырлар артеленә БАШ БУХГАЛТЕР КИРӘК. Тукай урамы, 41. Таткоопинсоюзның баш бухгалтерына килергә.
511—2—2